www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 19 (1384) 20 май 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

12

Чиләбедә яшәп иҗат итүче милләттәшебез Алена Әскәрова эшләрендә игелеккә өндәгән ислам дине рухы чагылыш таба.

16

Ватан сугышы ветераны, атаклы нәсел вәкиле, гобойчы Мөбарәк Батталовның төп иҗади тормышы опера театры оркестры белән бәйле.

24

Татарстан башкаласында узган чечен мәдәнияте көннәре бу милләт белән уртак якларыбызның бик күп икәнен раслады.

Калебләрне пакьләндереп торсак, Аллаһ йорты мәңге ак калыр!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районы Кирюшкино авылында Советлар Союзы Герое Мәхмүт Илач улы Аиповка, Башкортстанның Агыйдел шәһәрендә Советлар Союзы Герое Абдулла Шаһиевкә һәйкәл куелды.
- Кукмара районы Березняк авылы мәктәбендә шагыйрь Рәниф Шәрипов исемендәге яшь шигырь язучылар бәйгесе үтте.
- Казанда уза торган Халыкара Коръән уку бәйгесенең төп турына Евразиянең һәм Африканың 25 иленнән – 30 һәм Россия төбәкләреннән 20 кеше сайлап алынган.
- Башкортстанның Тәтешле районында Башкортстан һәм Татарстанның халык артисты Хәния Фәрхи исемендәге «Онытылыр димә...» халыкара фестиваль-конкурсы узачак.
- Мәскәү өлкәсенең Наро-Фоминск шәһәрендә журналист һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әнвәр Софинов белән хушлаштылар.
- «Татмедиа» династияләре» күргәзмәсе Казан федераль университетының икенче бинасындагы мәрмәр залда тәкъдим ителде.
- Россия ислам институтында яңа уку елыннан журналистика буенча магистрлык программасы ачылачак.
- Санкт-Петербургта «һөнәр палатасы» декоратив һәм гамәли сәнгать осталарының «Алтын җеп гасырлар аша узды» исемле күргәзмәсе ачылды.
- Зәй районы Сәвәләй мәдәният йортында Чаллы рәссамнар берлеге бүләк иткән картиналар күргәзмәсе ачылды.
- Болгар цивилизациясе музеенда рәссамнар Фиринат Халиков һәм Полина Илюшкинаның Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган күргәзмәсе ачыла.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Зиннур МАНСУРОВ, Татарстанның халык шагыйре:

«Совет чорында (Тукай турында) бик күп монографияләр эшләнде. Без хәзер шушы чорда барлыкка килгән фәнни хезмәтләрне тәнкыйтьләү-сүгү белән шөгыльләнергә тиеш түгел. Без ул идеология чорын beлəбез, әдәбият, галимнәр Совет идеологиясенә кертелгән булган. Алар тудырганның яхшысын алып, киләчәккә барырга тиешбез. Совет чорында чыккан Тукайның томлыкларын, аның искәрмәләрен укып карагыз әле – анда шайтан аягын сындырырлык әйберләр, бидгатьләр, гомумән, чәч үрә торырлык әйберләр бар... Без бүгенге заман боеклегеннән торып яңасын эшлик, искәрмәләрнең яңасын язык».

СЫНАМЫШЛАР

Май ае салкын килсә, игенгә туклык булыр, чебенгә юклык булыр ● Яз көне элек булмаган җирдән чишмә бәреп чыкса, җәй яңгырсыз килер ● 22 майда яңгыр яуса, уңышлы ел фаразлана; бу көнне бәрәңге утырталар ● 24 майда томан төшсә, юеш булса, яңгырлы җәй көтелә ● 25 майда таң кызарып атса, җәй эссе була ● 26 майда черки күп булса, солы уңа; аз булса, печән дә, ашлык та уңмый.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 23 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 57 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **16 сәгать 34 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **22 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **27 майда 16 сәгать 56 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

21 май – актёр, режиссёр, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәрит Рәфкать улы Бикчәнтәевкә 60 яшь (1962).

22 май – дәүләт эшлеклесе, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинга 75 яшь (1947);

– язучы, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Нәзифә Харис кызы Кәримова (Кашапова)га 75 яшь (1947).

25 май – рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рауль Вәли улы Нурмөхәммәтовның тууына 100 ел (1922–1988);

– шагыйрә, тәрҗемәче, филология фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Флёра Габдрахман кызы Тарханованың тууына 75 ел (1947–2018).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Майның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 22 май.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(22-30 май)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 майдан 27 июльгә кадәр** йөрәк һәм нечкә эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген шәүвәл аеның 19 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ



Рүзәл ЮСУПОВ, академик

Рәсми матбугат нинди?

Матбугат белемле һәм зәвыклы журналистлар тарафыннан чыгарылса, ул халыкның рухын баета. Безнең республикада татарча төрле газеталар чыгып килә. Дәүләт исеменнән чыкканнары да, хосусыйлары да бар. Хәер, аларның тиражлары күп миллионлаган татар халкы өчен бик аз: күбесенең ике-өч, өч-дүрт меңнән артмый. Халык газета укудан читләшә, чөнки дөньяны интернет, социаль челтәрләр басты. Аннары, кешеләрнең газета-журнал яздырып алырга акчалары җитми, өстәвенә, матбугат сатучы киоскларның күбесе бетерелде, авыл җирендә почталар эшләми. Гомумиләп әйтсәк, дәүләтнең халыкка матбугат ирештерү теләге дә юк бит.

Кешеләрнең газета-журналлар укудан бизүе һәм биздерелүе – аяныч хәл. Нәтиҗәдә халыкның рухи тормышы фәкыйрьләнә, сәяси активлыгы кими, гражданлык позициясе пассивлаша. Безнең хакимият иярләре, бу хәлне аңлап, халыкның сәяси карашын көчәйтергә, дөнья, ил хәлләренә, социаль тормышка карата фикерләрен активлаштырырга теләсә, матбугатны җанландырып, кешеләрдә газета-журнал уку теләген көчәйтә алыр иде. Бу изге ниятне тормышка ашыру чаралары да юк түгел.

Татарча матбугатны бик аз кешеләрнең генә уку сәбәпләренең берсе – бүгенге газеталарның күбесенең үз вазифаларын тулысынча үтәмәве, ягъни укучыларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндермәве. Бигрәк тә соңгы айларда чыккан матбугатның нигездә сай эчтәлекле, вак-төяк мәгълүматлы материаллар тәшкил итә, Украинадагы бәрелешләр шикелле дулкынландыра торган җитди мәкаләләр бик аз, дөнья һәм илебездәге вакыйгаларга анализ ясалган, кешеләрнең матди һәм рухи ихтыяҗларын күрсәткән язмалар юк диярлек. Мисалга, республикада иң күренекле саналган иҗтимагый-сәяси газетасының яңа гына (29 апрельдә) чыккан бер санына күзәтү ясап китик.

Газетаның беренче битендә көн үзәгендә торган мәсьәләгә яки мәсьәләләргә багышланган баш мәкалә юк. Икенче битендә Рөстәм Миңнехановның Мьянмага сәфәре турында мәгълүмат бирелгән. Татарстан өчен Мьянма белән хезмәттәшлекнең әллә ни мәгънәсе булмаса да, анда президентыбыз баргач, бу турыда хәбәр итми калу ярамыйдыр инде. Бу биттә шулай ук Владивостоктан юлга чыккан автомобильчеләрнең Казанга килеп җитүе турында «Бердәмлек чакрымнары» дигән репортаж урнаштырылган.

Өченче биттә «Ял өчен эшлисе бар», «Бурычлы хокуклар» дигән кечерәк кенә мәкаләләр һәм Айдар Шәйхин алып бара торган «Татарча сөйләшәбез» рубрикасында «Нәзарәт», «Зиярәт», «Онлайн» сүзләренә аңлатма бирелгән. Бу өч сүз аңлатмасы белән генә татарча өйрәнеп булуы бик шикле, әлбәттә. Дүртенче бит тулысы белән диярлек «Май кытлыгы» дигән мәкаләгә бирелгән. Газетаның бишенче битен «Кыйгак-кыйгак», «Бак-бак-бак» («Йорт казы акыллырак та, тәмлерәк тә») һәм «Чеби үстергәндә иң мөһиме – чисталык» дигән язмалар били. Алтынчы биттәге «Начар хәбәрләргә бәйлелек нәрсәсе белән куркыныч?» исемле язма авторы укучыларга матбугат чараларындагы тискәре эчтәлекле мәгълүматларны укымаска һәм карамаска киңәш дип киңәш бирә. Әйтерсең илдәге кимчелектән шундый юл белән генә котылып калып була икән.

Газетаның алдагы битләрендә «Йолдызнамә», «Сәламәтлек» («Каһвәгә ышаныч юк», «Һәр чәйнең – үз шифасы», «Яшәртә торган битлек», «Машинада күңел болганса»), «Серле сандык» («Кырыктан соң кимәскә», «Тәмле булсын», «Бакчачыга»), «Көн дә мең сорау» («Май аенда намаз вакытлары», «Ураза көндәлеге», «Ә син таныйсыңмы?» (Уен тексты һәм рәсемнәре), Атналык телевидение программасы, «Үпкәле туй», «Китмибез», «Төрлесеннән» дигән рубрикалы хәбәрләр һәм (инде ничәнче санда!) Люция Әблиеваның «Сөеп, сөелеп яшисем килә» исемле хикәясе урнаштырылган.

Шушы күрсәтеп киткән рубрика һәм язмаларның исемнәренә карап кына да, республикабызның иң абруйлы булырга тиешле газетасының 20 битлек бу санында халык тормышындагы җитди темаларга караган, туган тел, әдәбият, мәдәният, милли мәгариф проблемаларына багышланган, татар халкының фидакяр кешеләре, күркәм шәхесләре хакында һәм укучыларны дулкынландырырлык мәсьәләләр турында язмаларның юклыгын күрәсең. Бу газетаның башка саннарының да эчтәлеге, темалары шул чамада. Үзенең иҗтимагый-сәяси газета дигән статусына туры киләме бу? Гомумән, халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә, милләтебезнең мәдәнияте, мәгарифе, әдәбиятының алга баруына ярдәм итә аламы соң мондый газета? Бу сорауга уңай җавап көтү мөмкин түгел...

Шөкер, бездә эшчәнлегенә уңай бәя бирерлек берничә газета да бар. «Мәдәни җомга», «Безнең гәҗит» һәм «Татарстан яшьләре»ндә заман таләпләренә җавап бирерлек язмалар еш басыла. Мәсәлән, «Мәдәни җомга»ның 29 апрель санында Ренат Харисның «Укытучы – кеше җанының инженеры», Фоат Уразайның халыкара хәлләргә традицион рәвештә ясалган анализы, журналист Сөембикә Кашаповаының «Бер гасырлык «Казан утлары», «Тукай социамәдәни киңлектә», татар халкының асыл улларының берсе – армия генералы Алексей Антонов турында Рәис Зариповның «Сталинның хәрби киңәшчесе», Фәүзия Бәйрәмованың татар халкының күркәм милләт икәнлеген раслауга багышланган Михаил Худяков, Зөфәр Мөхәммәтшин тарафыннан халкыбызның олпат шәхесләреннән берсе Бакый Урманче турында гыйбрәтле мәкаләләр басылу – бик көтелгән җимеш. Илфат Фәйзрахманов нәширлегендәге «Безнең гәҗит» тә күп укучыларның мәхәббәтен яулый. «Татарстан яшьләре» дә актуаль темаларга кыю язмалар бастыра... Ләкин мондый газеталар аз. Күбесенең битләре әһәмиятсез, вак-төяк күренешләрне тасвирлауга багышланган материаллар белән тутырыла. Тормышның җитди мәсьәләләренә багышланган, халыкны борчыган вакыйгаларга төпле анализ ясалган язмалар сирәк күренә. Хәлбуки, хәзер дөнья һәм илебездәге вәзгыять бик четерекле. Мондый катлаулы шартларда кешеләрнең вакыйгаларга дөрес бәя биреп яшәвенә ярдәм итү – журналистлар бурычы. Алардан бүгенгенең хәвефле проблемаларын укучыларга кыю рәвештә аңлату таләп ителә.

Хәзер халкыбызның югары мәдәниятле милләт булып яшәве өчен – туган телебезне саклау, аның кулланылышын җәелдерү мөһим. Соңгы берничә елда татар теленең яшәешенә зур зыян тиде, бу күренеш әле дә дәвам итә. Телебезне мәктәпләрдә укыту системасы җимерелде: туган телен өйрәнүче балаларның саннары да кими, бу предметны укытуның сыйфаты да түбәнәя. Шулай ук телебезгә янаган зур куркыныч: туган телләрендә аралашучы татар кешеләренең саны да азая. Тел актив кулланылганда гына саклана, кулланылмаса, бетүгә, юкка чыгуга юл тота.

Димәк, хәзер барлык мәдәниятле, зыялы татарларның, беренче чиратта журналистларның изге бурычы – татар ата-аналарына татар мәктәпләренең санын арттыру, татар телен пропагандалау, аның әби-бабаларыбыз теле буларак кадерле ядкәр икәнлеген балаларыбызга өйрәтергә һәм ул телдәге газета-журналлар санын күбәйтергә кирәклеген аңлату зарур.

Татар журналистлары һәм зыялы милләттәшләребез алдында торган тагын бер бурыч – халыкның милли горурлыгын үятырга ярдәм итү. Ачы хакыйкать шул: татарларның күбесендә милләтебезнең нигезе туган телебезгә, милли мәдәниятка, мәгарифкә, мәгълүмат чараларына битараф караш хөкем сөрә. Әгәр моннан соң да милләт традицияләренә мондый караш хөкем сөрсә, татар халкын саклап калу, ихтимал, мөмкин дә булмас. Димәк, ашыгыч рәвештә халыкның үз милләтенә пассив карашын дәвалау, аны миллилек эчтәлеге белән тулыландыру таләп ителә.

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

ИСЛАМ ЯҢАРЫШЫНА – АК ЮЛ!

Урталык җирләре бүген хәтер түрендәге чал үткәненең тарихи сәхифәләрен яңарта. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар Татарстанда инде 2022 ел башыннан бирле уздырыла. Сан ягыннан алар хәзер иң югары ноктага җитеп килә һәм араларында хәтта халыкара әһәмияткә ия булганнары да шактый. Әйтик, бу көннәрдә «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit 2022» XIII Халыкара икътисади саммиты һәм Russia Halal Expo күргәзмәсе ачыла. Бүген, 20 майда, Казан Ратушасында «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышы узачак. Анда яңартылган «Казан басмасы» тәкъдим ителә һ.б. чаралар да карала. Казанда бүген шулай ук 10 мең кеше сыйдырышлы Җәмигъ мәчете төзелешенә тәүге таш салу тантанасы да була. Мәчеткә исем әлегә сайланмаган, һәм бу хакта карар халык фикерен өйрәнгәннән соң гына кабул ителәчәк икән. Миңа калса, «Ислам яңарышы мәчете» дигән исем моның өчен бүген һәр яктан караганда да күбрәк туры килер иде. Янә бер мөһим чара – Казанда бүген татар дин әһелләренең «Милли үзенчәлек һәм дин» дип исемләнгән XII Бөтенроссия форумы узачак. Ишарәле мәгънә салып, анда бөтен Россиядән 1100 имам чакырылган.

Искәртеп үтик, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган юбилей чаралары РФ президенты В.Путин карары нигезендә, федераль дәрәҗәдә үткәрелә. Федераль оештыру комитеты һәм республика төзегән эш планына 150 чара кертелгән. Алар арасында төрле конференцияләр, күргәзмә вә фестивальләр, бәйге, концерт вә спектакльләр дә бар. Юбилейга багышланган чаралар Россиянең башка төбәкләрендә дә уза һәм алар әле ел ахырына кадәр дәвам итәчәк икән. Болгарда исә төп тантаналар 21 майда була. Республика халкы һәм килгән кунаклар анда «Изге Болгар җыены»нда катнашачак. Биредә шулай ук 1100 еллык юбилей уңаеннан әзерләнгән почта маркасын рәсми төстә чыгару чарасы һәм Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 еллыкны әзерләү һәм үткәрү буенча федераль оештыру комитеты утырышын (аны РФ вице-премьеры М.Хөснуллин җитәкли) үткәрү каралган. «Ислам динен кабул итү» ядкәре куелган мәйданда ошбу тарихи вакыйганы тасвирлаган театральләштерелгән тамаша күрсәтеләчәк, җәмәгать белән өйлә намазы да укылачак. Ә Ак мәчет территориясендә «утлы шоу» тәкъдим ителәчәк. Казанда андый тамашаны «1000 еллык мәйданы» ягыннан Кремль диварында да күреп булачак икән. Әлбәттә, бәйрәм көннәрендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Мәдәният министрлыгы тарафыннан әзерләнгән башка чаралар да тәкъдим ителәчәк.

Инде илкүләм колач алган юбилей чараларына мөнәсәбәтне бүгенге кискен хәлләр һәм күпкырлы глобаль кризис күзлегеннән карап та белдерик. Цивилизацияләр бәрелеше һәм яңа дөньяви тәртип урнаштыру чорында яшәвебезне дә истә тотсак, исламның Урталык җирләренә, дөньякүләм диннәрдән тәүгесе буларак, моннан 11 гасыр элек рәсми рәвештә иңдерелүе, әлбәттә, зур тарихи, рухи вә геосәяси әһәмияткә дә ия. Ә бүген изге Болгар җирендә «Яңарыш» фонды тырышлыгы белән башкарылган киңкырлы һәм зур күләмле эшләр нәтиҗәсендә анда инде ислам яңарышы өчен ныклы нигез дә булдырылды. Бу җәһәттән, быелгы юбилей чараларын да шул юнәлештәге адым дип карарга нигез бар. Татарстан президенты Р.Миңнеханов әйтүенчә, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар Россия мөселманнарын берләштерүгә, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләренең бәйләнешен күрсәтүгә, шулай ук мөселман халыкларының гадәти кыйммәтләрен торгызуга юнәлдерелгән. Ул: «Юбилей дөнья җәмәгатьчелегенә безнең бай мәдәни һәм тарихи мирасыбызны, традицион рухи кыйммәтләрне саклау һәм үстерүдәге казанышларыбызны һәм Россия мөселман өммәте ислам дөньясының аерылгысыз өлеше булуын күрсәтергә тиеш», - дип саный. Ә бүгенге глобаль кризис шартларында ислам яңарышы аның тәүхиди-иҗтиһади асылын аңлап эш итүне дә күздә тота. Ул чакта инде, иншалла, хак динебез инсаниятнең илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүендә (димәк, төрле диннәр вә цивилизацияләр арасында гармониягә ирешүдә дә) рухи терәк һәм берләштерүче төп идея булып та хезмәт итә алыр.

Фоат УРАЗАЙ.

Сабантуйлар кайчан була?

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Сабан туен бәйрәм итү көннәрен раслады. Район үзәкләрендә һәм торак пунктларында 11-13 июньдә үткәреләчәк. Чаллыда Сабан туе 18 июньдә була. Казанда бәйрәм 19 июньдә узачак.

Мәскәүдә Сабан туе 2 июльгә билгеләнгән. Федераль Сабантуй Ульяновскида 17-18 июньдә узачак.

Рус теле комиссиясе дә булачак

Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча комиссиянең киңәюе көтелә. Яңа орган республика территориясендә яшәүче башка халыкларның телләрен саклау эшен үз эченә ала. Республика җитәкчесенең указы проекты Татарстан Хөкүмәте сайтында чыкты.

Яңа комиссияне дә Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов җитәкләр дип көтелә, ә аның урынбасары шулай ук мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин булачак.

Комиссия составына башкарма комитетлар, республика министрлыклары, ведомстволары, мәдәният, дин эшлеклеләре, Татарстан югары уку йортлары һәм гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре, аерым алганда, «Татмедиа» агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев һәм башкалар керәчәк.

Шулай ук республикада Татарстан Президенты каршында Рус теле комиссиясен төзергә ниятлиләр. Хөкүмәт порталында дөнья күргән документта билгеләп үтелгәнчә, әлеге комиссия «Рус теленең кулланылышын тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр белән үзара бәйләнешен оештыру максатыннан» төзелә.

Указ проектында булачак комиссиянең составы да китерелгән. Аны Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин җитәкләр дип көтелә.

Динара татулыкка үрнәк

Татарстан Иҗтимагый палатасында «Идел буенда поликонфессиональ мохит һәм диалог культурасын формалаштыруда Идел буе Болгарының ислам кабул итүе» темасына түгәрәк өстәл утырышы узды.

«Россия күп конфессияле җәмгыяте асылын исламсыз аңлап булмый, чөнки Россия милләтен формалаштыруда мөселманнар да катнашкан, – дип сөйләде анда Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов. – Танылган галим Морад Рәмзи 1908 елда «татар имамнары һәрвакыт сөнниләр, матуридилар булган һәм гамәлләре ханәфи мәзһәбенә туры килгән» дип язган».

Идел буе һәм Россиянең күпчелек өлеше мөселманнары гасырлар буе бүлсынган ханәфи мәзһәбе төрле культура һәм диннәр үрелешендә туган.

Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева фикеренчә, Россиядә төрле конфессия һәм халыкларның тату яшәве буенча уникаль тәҗрибәне әле яхшылап, җитәрлек кадәр күрсәтә, сөйли белмибез. «Каядыр тарихи мәчетләрне халыкка тапшыру, каядыр яңаларын төзү – юбилей чаралары РФ Президенты дәрәҗәсендә үткәрелүе белән әһәмиятле. Россиянең тарихи тәҗрибәсенә каршы чыгулар да булырга мөмкин, ләкин аны барыбер дөньяга күрсәтү кирәк», - дип ассызыклады Зилә Вәлиева.

Казанда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы фотохәбәрчесе Солтан Исхаковның Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуга багышланган фотокүргәзмәсе ачылды.

Истәлекле көнгә фотокүргәзмә

«Хакыйкатьне танып-белү» («Познание истины») дип аталган күргәзмә башкаланың Дәрвишләр бистәсендә Сәетгалиев исемендәге Мәдәният сараенда оештырылды. Солтан Исхаков биредә озак еллар «Казан» фотоклубын җитәкли. Күргәзмәдә Идел буе мөселманнарының дини тормышын һәм рухи мәркәзе булган борынгы Болгар шәһәрлеген чагылдырган утыздан артык фотография урын алган.

Күп кенә фотографияләрдә Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев сурәтләнүе бер дә гаҗәп түгел. Соңгы елларда борынгы Болгар шәһәрлегендәге ядкәрләрне саклау өчен, республиканың Дәүләт Киңәшчесе җитәкчелегендәге «Яңарыш» тарихи һәм мәдәни истәлекләрне торгызу фонды тарафыннан күп эшләр башкарылды.

С.Исхаковка күргәзмә ачылышы уңаеннан М. Шәймиев исеменнән котлау сүзләрен Дәүләт Киңәшчесенең ярдәмчесе Нурсөя Шәйдуллина җиткерде.

Күргәзмә ачылышында Казан фотографлары, «Казан» фотоклубы әгъзалары, фотография сәнгатен сөючеләр, Дәрвишләр бистәсендәге «Ислам» мәчете мәхәлләсе мөселман җәмәгатьчелеге катнашты.

Лилия ГАДЕЛШИНА.

Үзеңне сынап кара

Россия ислам институты Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан милли тематикага фотобәйге оештыра. Конкурска эшләр 31 майга кадәр кабул ителә. Катнашучылар 12-20 яшьлекләр һәм 20-60 яшьлекләр категорияләренә бүленә. «Җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр каралган».

12-20 яшьлекләр «Туган як табигате» һәм «Гаиләмдә милли бәйрәмнәр» номинацияләрендә, ә 20-60 яшьлекләр «Татарстан мәчетләре» һәм «Россия мөселман халыкларының милли бәйрәмнәре» номинацияләрендә фотографиягә төшерү осталыкларын сынап карый ала.

Фоторәсемнәр konkursrii@yandex.ru электрон адресы буенча кабул ителә.

Татарстаннан читтә яшәүчеләр игътибарына

*2022 елның икенче яртыеллыгына **«Мәдәни җомга»** газетасына Татарстаннан читтәге өлкә-республикаларда да – Башкортстан, Оренбург, Ульяновск, Төмәндә һәм башка төбәкләрдә язылып була. Газетабыз электрон каталогка кертелгән **(язылу индексы – П8254)**. Игътибар! **«Мәдәни җомга»** газетасын почта бүлекчәләрендә электрон каталогтан эзләтегез.*

1 нче биттә – Болгардагы Ак мәчет. Фото: wikimedia.org

Чеченнәр кунак булды

Чечен Республикасы мәдәният министры Айшат Кадыйрова катнашында Татарстанда чечен мәдәнияте көннәре үтте.

Кавказ төбәге республикасы делегациясе вәкилләре Татарстаннан милли театр студияләре идеясен алган, Милли китапханә эшчәнлеге белән кызыксынган.

Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова һәм Чечен Республикасы мәдәният министры Айшат Кадыйрова ике республиканың алга таба кайсы юнәлешләрдә хезмәттәшлек итә алуы хакында фикер алышты.

«Төп уртак ягыбыз – дин. Республика җитәкчеләренең дуслыгы безгә өстәмә импульс бирә. Безнең беренче Президентыбыз: «Мәдәниятсез милләт юк», дип әйтә иде. Шушы лозунг нигезендә мәдәниятебезне тиешле югарылыкта тотарга омтылабыз», – диде Чечен Республикасының туризм буенча министры Мөслим Байтазиев.

И.Әюпова Чечен Республикасына «Федерация» милли театрлар фестивалендә Татарстан театрларын яхшы кабул иткән өчен рәхмәтләрен җиткерде. «Сез милли театрлар фестивале үткәреп дөрес юл сайлагансыз. Театр ул – традицион мәдәниятнең яңа югарылыкка күтәрелүе. Без алга таба да бик рәхәтләнеп бу фестивальдә катнашыр идек. Театрлар аннан рухланып кайта», – диде ул. И.Әюпова республикада халык театрлары күп булуын һәм алар өчен махсус фестиваль оештырылуын әйтте: «Бу мәсьәләдә зур тәҗрибәбез бар – без бүлешергә әзер. Без хәзер балалар өчен дә шундый театр студияләре ачабыз. Бу телне саклау инструменты да».

Татарстан министры Милли костюм театры юнәлешендә уртак проектлар булдырырга чакырды. Кунаклар идеяне хуплап, үзләренең театраль милли киемнәрне реставрацияләү өлкәсендә тәҗрибәләре булуын да әйттеләр. Чечен делегациясе халык мирасы булган бик күп кулъязмаларның югалуын, аларны күрше республикаларның архивлары аша да эзләтүләрен әйттеләр. «Безгә чечен халкына кагылышлы бөтен мәгълүмат кызыклы», диде алар. Татарстан да тугандаш халыкка ярдәм итү максатларында үз архивларында чечен халкы мирасына бәйле кулъязмалар булу-булмавын барлап чыгачак.

Чечен Республикасы мәдәнияте көннәре Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концертлар залында республиканың 100 еллыгына багышланган концерт белән тәгәлләнде. Тамаша Аднан Шахбулатов исемендәге Чечен дәүләт филармониясе коллективы һәм артистлары белән оештырылган иде. Концерт башында тамашачыга чечен мәдәнияте турында мәгълүмат бирелде. Казан тамашачысы алдында Чечен халык уен кораллары оркестры, «Илли» ирләр хор капелласы, Балалар симфоник оркестры, Чечен Республикасының халык артисты Мурад Майкиев, атаклы «Вайнах» академик бию ансамбле һ.б. чыгыш ясады.

Талант иясе иде

Татар халкы зур югалту кичерде. 14 майда, милләтебезнең танылган улы, Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Ислам улы Ибраһимов вафат булды.

Ул 1947 елның 20 ноябрендә Украинаның Львов шәһәрендә туа. Гаиләләре белән Казанга кайтканда, Ренатка 5 яшь була. Ул музыка мәктәбендә домра классында белем ала, кечкенәдән үк классик арияләр һәм җырларны җырлап үсә. Уналты яшеннән үзешчән эстрада оркестрында җырлап йөри. Казан дәүләт консерваториясендә икееллык әзерләү бүлегендә укыганнан соң, вокал бүлегенә укырга керә. М.Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли, эстрадада чыгышлар ясый.

Р.Ибраһимов 1975 елда Сочида узган «Красная гвоздика» конкурсыннан соң танылa. 1993 елда ул «Итальянский контракт» фильмында төшеп актер буларак та ат казана. Соңрак сәнгатькяр үзенең җыр театрын оештыра, продюсерлык эше белән шөгыльләнә.

Р. Ибраһимов һәрвакыт үз халкына, мәдәниятенә, сәнгатенә тугры калды. Ул татар җырларын башкарып, моңнарыбызны башка милләтләргә дә танытты. Үзенең гаиләсендә дә милли гореф-гадәтләребезне саклап, балаларны күңеленә сеңдерергә тырышты. «Иҗаты Татарстанның гына түгел, ә бөтен илнең казанышына әверелгән якты шәхес һәм талант иясенең арабыздан китүе белән килешүе кыен. Ренат Ибраһимов югары сәхнә мәдәниятенә һәм артистларга хас сөйкемлелеккә ия кеше. Табигать Ренат Ибраһимовка беркемнеке белән дә бутап булмый торган гаҗәеп тавыш бүләк иткән.

Ренат Ибраһимов безнең күңелләрдә, җырчының талантына баш иючеләрнең йөрәкләрендә тулы бер чорның символы, югары сәнгать һәм үзе сайлаган эшкә тугрылык үрнәге булып калачак», – диелә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов җырчының гаиләсенә юллаган кайгынамәдә.

Хәтер көне – дога көне

Кол Шәриф мәчетендә Татарстан Диния нәзарәте Аксакаллар шурасы утырышы узды. Утырышта кабул ителгән резолюциядә шәвәл аеның 13нче көнендә Хәтер көнен билгеләп үтү расланды.

«Хәтер көнен һәр елны ай календаре белән барлык мәчетләрдә, мәхәлләләрдә үткәрүне дәвам итәргә. Шул көнгә багышланган вәгазьләр сөйләргә һәм намаздан соң җирлектәге изге урыннарга барып Коръән укып дога кылырга», – дип теркәлгән резолюциядә.

«Без бу көндә 1552 ел корбаннарын гына түгел, ә ул чордан соң булган бөтен сугышларда, репрессияләрдә һәлак булган милләтәшләребезне һәм дин кардәшләребезне дә искә алабыз», – диде Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов. – Хәтер көнен быел күп кенә районнарда да билгеләп үтәбез. Киләсе елларда һәр мәчеттә дога кылуны оештырачакбыз».

Утырыштан соң Казан Кремлендә Олуг Мөхәммәд улы Мәхмүт хан һәм Мөхәммәд Әминнең җәсәдләре җирләнгән кабер-төрбә янында 1552 елда Казан ханлыгы алынганда һәлак булучылар истәлегенә дога кылып, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Диния нәзарәте Аксакаллар шурасы Хәтер көнен билгеләп үтте.

Казан ханлыгының башкаласы 1552 елның 12 октябрендә алына. Татарстан Диния нәзарәте быелтыр июль аенда бу датаны дини – һиҗри календарь белән билгеләп үтәчәген белдергән иде. Шәүвәлнең 13 нче көне быел 14 майга туры килде.

● Суринам Республикасы аборигеннары нибары 340 сүз ярдәмендә аралаша. Рус телендә 500 мең сүз (махсус терминнардан башка), инглиз телендә 1 миллион сүз бар.

● Французлар сузык авазларның төсмерләре саны белән таң калдыра. Мәсәлән, чын француз «о» сузыгын 13 төрле әйтә ала.

● Көньяк Африка Республикасында 11 дәүләт теле бар.

● Карачай-Чиркәс Республикасындагы абаза теле дөньяда иң катлаулы тел буларак Гиннесснең рекордлар китабына кертелгән.

● «О» хәрефе дөньяның 65 телендә бар.

● Дөньяда иң популяр телләр – инглиз һәм кытай телләре. Беренчесендә барлыгы 1,13 миллиард кеше, икенчесендә 1,11 миллиард кеше сөйләшә.

Татарстан архив эше буенча дәүләт комитеты дүрт ел элек, татар халкында һәр кеше үзенең җиде буын әби-бабасын белергә тиеш, дигән буыннардан-буынга әманәт кебек тапшырылып килгән гореф-гадәтне яңартып, «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» дигән республика шәҗәрә фестивален уздыра башлаган иде. Быел шәҗәрәләр фестивале республикада дүртенче тапкыр үтте. Дүрт ел дәверендә анда республиканың 43 районыннан 162 гаилә катнашкан. Конкурс быел да башта барлык район үзәкләрендә һәм аннан соң Чирмешән, Яңа Чишмә, Саба, Яшел Үзән, Тукай зоналарында һәм Казанда узган. Аларда Татарстанның 36 районыннан һәм шәһәр округларыннан 36 гаилә бәйге тоткан.

Тату гаилә – бәхет нигезе

Быел шәҗәрә конкурс-фестиваленең йомгаклау тамашасы Камал театры бинасында узды. Анда зона этапларында җиңүгә ирешкән 6 гаилә – Бөгелмә районыннан Малыхиннар, Алабуга районыннан Сәркаровлар-Эмирбәковлар, Яңа Чишмә районыннан Газыймовлар, Саба районыннан Ахунҗановлар, Буа районыннан Латыйповлар, Казаннан Дыкиннар гаиләләре үз шәҗәрәләре куелган стендларын, йолаларын, аш-суга осталыкларын, нәсел гореф-гадәтләрен тәкъдим итте. Фестивальдә катнашучыларны һәм җиңүчеләрне Татарстан җитәкчелеге исеменнән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сәламләде.

Өч тапкыр алфавит алмаштырган татар халкы өчен шәҗәрә төзү шактый катлаулы. Шуңа да нәсел агачын барлаучыларга латин графикасын, гарәп имлясын белергә, документлар табарга кирәк. Ә моның өчен кайсы метрика китабының шәҗәрәңә килеп тоташканын чамалау сорала. Фестивальдә катнашкан һәр нәсел менә шундый четерекле эшне уңышлы башкарып чыккан.

Конкурсның йомгаклау этабында катнашкан гаиләләрнең һәркайсының үткәне, бүгенгесе үрнәк булырлык. Яңа Чишмә районыннан Газыймовлар гаиләсен республикада белмәгән кеше сирәктер. Мидхәт ага Газыймов - озак еллар авыл мәктәбендә тарих укытучысы булып эшләп, үз халкының үткәнен өйрәнеп, авыл музеена нигез салган (анда кулдан тукылган һәм чигелгән борынгы сөлгеләр генә дә 350 данә), бәетләр җыеп, тарихка кагылышлы китаплар чыгарган шәхес. Хәзер аның игелекле эшчәнлеген балалары, оныклары, туган-тумачалары, шәкертләре дәвам итә, XIX гасыр үрнәкләре белән намазлыклар, сөлгеләр, милли күлмәк-алъяпкычлар чигәләр, заман сандыгын булдыралар. Мидхәт абый Зирекле авылыннан Гражданнар сугышы бәрелешләрендә катнашкан, Бөек Ватан сугышы яуларында һәлак булган авылдашлары турында да мәгълүматлар бөртекләп җыйган.

Буа районының Яңа Чәчкап авылыннан Латыйповлар нәселе 18 буынын барлый алган. Алар бу эшне 1990 елларда башлап җибәргән. Шушы шәҗәрәнең бер яфрагы булган Гөлмира Нәгыймуллина мәктәптә тарих укыта һәм шул чакта укучылар белән шәҗәрәләр төзү буенча шөгыльләнә. Нәсел агачларын барлаган вакытта гаиләләренең гарәп имлясында язылган шәҗәрәсен таба. Ул Үзбәкстаннан күченеп кайткан кешеләрдә сакланып калган. Борынгы документлар Яңа Чәчкапта 1931 елда авылда чыккан янгында юкка чыккан. Ул фаҗигадә 81 йорт янган. Гөлмира ханым 1829 елгы ревизия кенәгәләреннән материаллар туплый, шул ук вакытта 1845 елда авылга мулла итеп җибәрелгән Рәхмәтулла бабай теркәгән мәгълүматларны – метрика кәгазьләрен дә табалар. Аннары беркадәр материал Латыйповлар шәҗәрәсенең бер тармагы булган Нурулла Бикмуллин эзләнеп язган «Туган авыл – туган туфрак җылысы» дигән китаптан да табыла. Моннан тыш шушы нәселдән булган яшьләр, Буа, Казан архивларында казынып, материалларны тулыландыруны дәвам итә. Фестивальгә куелган стендта исә нәсел шәҗәрәсе аеруча киң тармаклы булуы, буыннар тирәнлеге белән хәйран итә. Былтыр Н. Бикмуллин үзе эзләнеп язган «Яңа Чәчкап авылы: ата-баба нигезе» дигән тарихи хезмәтне дә китап итеп чыгарган. Анда авылның һәр йорты – гаиләсенең тарихы барланган. Нәсел Бурлы дигән аты белән дә дан тоткан. Ул күп бәйгеләрдә алдан килә торган булган, күп затлы бүләкләр алган. Нәселнең төп ядкәре исә 1920 елларда Тәтеш Сабан туенда ат ярышында җиңгән өчен бирелгән 1912 елгы Тула самавыры.

Саба районының Олы Шыңар авылыннан килгән Ахунҗановлар да үзләренә 13 буынын барлаган шәҗәрә белән җәлеп итте, анда нәселнең 707 кешесе ачыкланган. Гаиләнең горурлыгы – сәүдәгәр Ахунҗан бабай. Ул болганчык, ачлык елларында халыкка бик булышкан, шуның белән авылдашларының да күңелен яулаган. Ахунҗан бабайның 10 баласы була. Аны 1931 елда сөргенгә сөргәннәр. Әтиләрен авырлыклардан саклау ниятеннән аңа ике баласы ияреп китә. Сигез туган Олы Шыңар авылында яшәп кала. Нәсел еллар белән тагын да ишәя, алар Россиянең Кемерово, Алабуга, Чаллы, Казан, Иркутск калаларында яшиләр. «Хәзерге вакытта Олы Шыңарда һәм якынтирә авылларда Ахунҗанов фамилияле дәрәҗәле 18 гаилә гомер кичерә», – ди Миңгәр күмәк хуҗалык җитәкчесе Ришат Ахунҗанов. Бүген шушы нәселгә караган барлык кешеләр җыелып, аралашып яши. 20 ел элек, Ахунҗан нәселен җыеп, авылда Сабан туен да уздырганнар. Быел да нәсел кешеләре белән бергәләп милли бәйрәмебезне үткәрергә ниятлиләр. Камал театрында Ахунҗановлар нәсел шәҗәрәсен 75 кешелек делегация тәкъдим итте.

Казанның Вахитов районыннан Гөлмира һәм Антон Дыкиннар үз гаиләләре шәҗәрәсен тәкъдим итте. Бу гаилә музыкальлеге белән аерылып тора, нәселдән бик күп музыкантлар чыккан. Алар - Татарстанның дирижер А.Сладковский җитәкчелегендәге академия симфония оркестры артистлары. Дыкиннар жюри игътибарына гаилә ядкәрләре – борынгы фоторәсемнәр альбомын, архив документларын, 1943 елгы хатлар һәм открыткалар тәкъдим итте. Иң кадерле истәлек исә Антон Дыкинның бабасыннан мирас булып калган XVIII гасыр скрипкасы. Әби-бабаларын искә алу традициясен Дыкиннар гаиләләрендә яратып әзерләнә торган каз һәм ат итләре бәлешен, кабак бөккәне аша күрсәтте.

Алабуга районыннан Сәркаровлар-Эмирбәковлар лезгин һәм татар гореф-гадәтләрен саклаулары белән истә калды.

Бөгелмә районының Соколка авылыннан Малыхин-Ковальчуклар гаиләсен фестивальдә дүрт буын вәкиле бергәләп тәкъдим итте. Алар хәзерге вакытта нәселнең 247 кешесен ачыклаган. Малыхин-Ковальчукларның әби-бабалары Соколкага Курск губернасыннан килгән булган. Алар тәкъдим иткән ядкәрләр арасында бер гасырдан артык вакыт элек тукылып тегелгән милли костюм игътибарны җәлеп итә. Гаиләдә шулай ук борынгы икона да саклана. Малыхин-Ковальчуклар аның белән яшь парларның гаилә корулары фатиха бирә. «Алар барысы да бәхетле гомер кичерә», – ди Любовь Малыхина.

Фестивальнең финал бәйгесендә катнашкан һәр гаилә сәхнәдә үзенең нәсел гореф-гадәтләрен һәм йолаларын чагылдырган сәхнәләштерелгән күренеш белән чыгыш ясады.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, фестивальгә йомгак ясап, гаилә кыйммәтләре һәм гореф-гадәтләренең җәмгыять үсешендә мөһим роль уйнавын искәртеп үтте. «Фестиваль шәҗәрә традицияләрен саклауга, гаилә элемтәләрен һәм буыннар бәйләнешен ныгытуга, нәсел тамырларына һәм туган як тарихына кызыксыну уятуга юнәлтелгән. Әгәр бу эшкә бүгенге кебек игътибар бирүне дәвам итсәк, балаларыбызның киләчәге ышанычлы кулларда булыр», – диде ул.

Бәйге-фестивальнең җиңүчеләре дип Саба районыннан Ахунҗановлар гаиләсе игълан ителде. Икенче урынны Буа районыннан Латыйповлар яулады. Өченче призлы урынга исә Бөгелмә районыннан Малыхиннар ия булды. Җиңүчеләргә бүләкләрне Ф.Мөхәммәтшин тапшырды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Игътибарга лаек иҗат

(Гүзәл Әдһәм әсәрләренә күзәтү)

Татар әдәбиятында халыкның күңел байлыгы каләм тибрәтүчеләрнең иҗат җимешләре белән дәлилләнә. Гүзәл Әдһәм иҗаты белән танышкач, шушы фикергә инанасың.

Гүзәл Әдһәм – тематик байлык җәһәтеннән дә, фикерләренең куәте ягыннан да әдәбият мәйданында бик күпләрне бәйгегә чакырырлык, беркемне дә кабатламаган үз иҗади йөзе булган язучы. Ул төрле жанрларда каләмен сыный һәм берсендә дә сынатмый. «Наласа авылы көе» (2012), «Асылмалы күпер» (2012), «Әбием ни исемле?» (2017) җыентыкларында, газета-журнал битләрендә чыккан новеллалары, повестьлары, драма әсәрләре һәм балалар өчен язылган хикәяләре киң катлам укучыларның мәхәббәтен яулады.

Язучы иҗатында даими, эзлекле итеп күтәрелгән тема-проблематика – мәхәббәт. Табигатьтәге һәрнәрсә бары тик «ярату», «сөю», «сөелү» дип аталган могҗизалы хисләр чолганышында яшәргә яратылган. Мәхәббәт темасына кагылышлы идеяләрен автор төрле пафосларда яңгырата. Мәхәббәт, аеруча тәүге сөю хисе, ташкындай бөтерел ала. Тик мондый хис өермәсеннән күз дә томалана шул. Сафлыкны, намусны, гыйффәтне югалтуы бик тиз, яңадан табып кына булмый. Ни кызганыч, гөл кебек нәфис күңелле кыз балаларның саф өмет-хыялларын аяк астына салып таптауны бернигә дә санамаучы тупас хайвани табигатьле адәмнәр табылып тора. Берәүләр бу фаҗигане сабырлык белән кичерергә көч таба, тормышка мәхәббәтләрен сүндермичә яши. Әмма рухы сынганнары да, күңеле гомерлеккә гарипләнгәннәре дә бар. Тапталган намустан калеб тә карала. «Икәү» хикәясенең вакыйгасы шушы фикерләргә мисал булып тора. Кондуктор Әлфия кайчандыр шәфкать туташы булган. Яшьли намусын югалткан, бәхетен җуйган хатынга хәзер актан киенгән һәр кыз - дошман. Бу кара хисен ул тыеп кала алмый. Сөйләшеп аңларга мөмкинлек булса да, сабыен үлемнән саклап калган шәфкать туташын автобустан төртеп төшерә.

Хатын-кыз үз кадерен белеп яшәргә тиеш. Моның өчен горурлыкны һәр очракта сакларга туры килә. «Әкълимә» хикәясендә Әкълимә очраклы рәвештә беренче мәхәббәте белән очраша. Хатын-кыз турында ямьсез сүз ишеткәч, күңелендә кубарылган дулкынландыргыч халәте бик тиз уза.

Исәп-хисапка, дан-дәрәҗәгә корылган мөнәсәбәтләрдә мәхәббәткә урын юк («Зәңгәр кашлы көмеш алка»). Мәхәббәтнең тарту көче зур. Хәтта җавапсыз булса да. Авторның байтак геройлары җавапсыз мәхәббәттә яна, көя. Алар, шушы халәтләрен дә бәхет санап, сабырлык белән яши. Иснеме җисеменә туры килгән «Тарту көче» хикәясендә менә шундый мәхәббәт тарихы урын алган. Автор аны фаҗигале пафоста яңгырата. Асия укытучы Зарифка гашыйк була, әмма Зариф икенче кызга өйләнә. Сугыш башлана. Зариф хәбәрсез югала. Хатыны икенче кешегә кияүгә чыга. Авылга «Зариф исән икән. Госпитальдән авылга алып кайтырга кушканнар» дигән хәбәр килә. Мәхәббәтенә тугрылык саклаган Асия ике аяксыз калган инвалид ирне госпитальдән егерме чакрым тартып алып кайта.

«Сылу исемле кыз» хикәясенең сюжеты исә мәхәббәт белән янәшә торган ихлас дуслык хисен зурлый. Сылу белән Данир техникумда очраша. Дамир бер күрүдән кызга гашыйк була. Әмма ул үзе Сылуның хыялындагы егеткә охшамаган шул. Аның күңеле башкага тартыла.

Яратышып, бергәләп корган оялар байтак очракта юк кына сәбәпләр аркасында таркала. Һәр каршылыкны сабырлык белән хәл итәргә, хәтта сәбәбе үтә җитди булса да, аңлашырга мөмкинлек калдырырга кирәк («Сөйгәнем куркак куян»). Кайбер очракта олы җанлылык, гафу итә белү дә кирәк. Гаилә тотрыклыгын саклауда һәркем (ир, хатын, ике яклап әти-әни, туганнар,балалар) бурычлы. Автор бу фикерен гыйбрәтле вакыйгалар, үрнәк образлар аша яңгырата.

Яшь буын белән өлкәннәр арасындагы мөнәсәбәт – Г.Әдһәм иҗатына хас үзәк темаларның берсе. Авторның әни-әти, кайнана-кайната буларак сурәтләнгән геройлары яшьләргә акыллы, төпле киңәшләрен бирә. «Әллә нигә сине юксынам» хикәясендә акыллы кайната, киленеңең гаепсез булуын аңлап, улының гаиләсен саклап калырга ярдәм итә. Күп әсәрләрдә килен белән кайнана, җаннарын кузгаткан йөрәк серләрен бушатып, юаныч табып, уртак кадерле кешеләрен югалтканнан соң бер-берсенә терәк булып хәрәкәт итә («Ир җылысы», «Ястык»).

Ни кызганыч, адәм балалары арасында яхшылыкны тиз онытканнары да бар. Әле ярый, кайберәүләр ялгышып ала да, соңыннан тәүбә-үкенеч хисе кичерә. «Ир җылысы» хикәясендә менә шундый бер гыйбрәтле хәл бәян ителә. Ире мәңгелеккә күзен йомган мизгелдә Рәсимәнең йөрәгеннән үкенечле бер хис көйдереп үтә. Танышуларыннан башлап, гомер буе иренең, аның туганнарының җылысына кинәнеп яшәде бит ул. Ә үзе берара «Мин аларның барысын да сине яраткан кебек яратам» дигән иренә, аның мәрхәмәтле туганнарына тар күңеллек күрсәтеп алды. Шушы гамәле сәбәп булмадымы икән пар канатының яшьли китеп баруына? «Үксү» хикәясе исә моңа капма-каршы вакыйганы тасвирлый. Килен кайнанасын гомер кичергән өеннән куып чыгара. Ә бит кайчандыр бу олы йөрәкле хатын киленне, ул вакытта яшь кызны, хурлык тамгасыннан саклап кала. Аны улы белән кавыштыра. Бу хәлне бер тапкыр да искә алмый, «Бу яхшылыгыны беркайчан да онытмам» дигән вәгъдә онытыла. Иң аянычлысы да шул, кайнанага икенче килен дә мәрхәмәтсезлек күрсәтә. Югыйсә, бу ана икесенә дә итагатьле ирләр үстереп биргән, балаларын тәрбияләгән, аякка басарга ярдәм иткән. Шулай да карчыкны өйгә кертергә туры килә. Әбисенә сугыш ветераны-ның хатыны буларак квартира эләгү мөмкинлегенә өметләнеп, шәһәрдән бер оныгы кайтып төшә. Ләкин инде сусызлыктан, ачтан, бигрәк тә мәрхәмәтсезлектән әлсерәгән карчык мәңгелеккә күзләрен йома.

Г.Әдһәм иҗатына хас эчтәлекнең тагын бер үзенчәлеге шунда: автор гаилә һәм бала, остаз һәм укучы, өлкән буын һәм яшьләр проблемаларына максатчан игътибар юнәлтә, сабый, яшүсмер образларын якын итә. Һәр әсәрендә җаваплылык тойгысын зурлый.

Балалар язмышына игътибар авторның биографиясе, тормыш тәҗрибәсе, тормыш итү тәртибе белән бәйле. Г.Әдһәм укытучылар гаиләсендә туып-үсә. Үзе дә бу һөнәрне сайлый. Мәктәп-гимназияләрдә мөгаллимә булып эшли. Алабуга педагогика институтында студентларга белем бирә. Ире Ринат белән өч бала тәрбияләп үстерә. Педагог һәм ана буларак, ул бу проблемаларны тирән аңлый. Ир белән хатынның аерылышуы, гаиләдә әти булмавы иң башлап бала күңеленә тирән яра сала. Әйе, тулы бер буын балалары әтиләренең сугыштан кайтуын тилмереп көтте, ата-ананың тигез канаты астында яшәргә өметләнде («Сәйдә, сиерчык һәм яз», «Язлар җиткәч кайтырмын»). Сугыш ятимлеге исәннәрнең әле хәзер дә йөрәген әрнетә. Ә менә бүгенге тыныч тормышта ятимнәрнең артуын ничек аңларга? Сыңар канатлы гаиләдә яшәгән баланың бәхете, хәтта үги әтисе тәрбиясендә яхшы мөнәсәбәт тоеп яшәсә дә, тулы була алмый. Һәр баланың күңеле үзенекенә тартыла. Автор әлеге фикерен һәрдаим ассызыклап бара.

Җир йөзендәге җан ияләренең явызлары – хаклык һәм тугрылыкны аңламый торган бәндәләр. Алар дөнья малы өчен башкаларның тормышын җимерә, үч тота, мәкерле тозак кора. «Тыкрык» повестенда Сәгадәт шундый явызлар кылган гамәлләр аркасында бихисап михнәтләргә дучар була. Ләкин горурлыгын, хатын-кыз намусын соңгы чиккәчә саклый. Г.Әдһәмнең көчле рухлы геройлары максатларына ирешүдә зәгыйфьләрне таптап үтми.

Язучының сәнгатьчә фикерләре милләтнең асыл сыйфатларына, гореф-гадәтләренә, аңына барып тоташа. Аларның дөньяви һәм гамәли чагылышын туплаган образ-детальләр аш-су, кигән кием, өй бизәлеше (ак ялук, шәл чуклары, милли бизәкләр, намазлык мендәр чиләк-көянтә) әсәрләр тукымасында мулдан кулланыла. «Алмалы көянтә», «Ястык» хикәяләре бу фикергә ачык мисал булып тора. Әсәр тукымасына җәйлы гына урын алган код-детальләр, мәкаль-әйтемнәре татарның образлы фикерләү үзенчәлекләрен ача. «Әтнәби» хикәясенең үзәк герое Лиза балалар йортында тәрбияләнгән. Бәхетенә, язмыш аны Нәфисә карчык гаиләсенә якынайта. Лиза һәр эшендә әлеге мәрхәмәтле гаиләдә кагыйдә итеп алынган тәртипләрне рухи-әхлакый кыйбла итәргә тырыша. Нәфисә карчык үз балаларын да, Лизаны да «Өең кетер булсын, өс-башың кетер булсын». Эшләгән эшең кетер булсын», «Авызың тулы кан булса да, читләр алдында төкермә» дип өйрәтеп калдыра. «Ястык» әсәрендә ястык образына да авторның мөһим фикере салынган. Ястык образы туры мәгънәдә кайнананың үз кызы, сердәше булып яшәгән килененә соңгы бүләге буларак сурәтләнгән. Әлеге килен инде үзе кайнана, җиде оныкның әбисе. Ул зур ястыктан җиде мендәр тутыра. «Мин беләмле» заманча улының һәм марҗа килененең мендәрдә йоклауны өнәмәвен тойса да, оныкларын шушы мендәрләргә яткыра, аларның җылылыкта таралып йоклауларына сөенә. Автор шул рәвешле гади генә ястык образын халык аңының, тәртибенең коды рәвешендә файдалана, буыннар дәвамлылыгының символы итә.

Г.Әдһәм – тарихи вакыйгаларга, сәяси-иҗтимагый хәлләргә сизгер күңелле, өлгергән карашлы язучы. Аның әсәрләренең идея-эстетик эчтәлеге әхлакый каршылыклардан күпкә киңрәк. Автор гаять җитди проблемаларны да үзенең аңы, тәҗрибәсе, белеме, акылы белән кыю рәвештә яңгырата. «Тыкрык» повестенда потенциал халык дошманы сылтавы белән сөргенгә җибәрелгән Гыйззәтулла хәзрәт, аның асрамага алынган, кыска гына гомерендә бер рәхәтлек тә татымаган кызы Сәгадәт, Сәгадәтнең уналты яшеннән сугыш кырында кан түккән, гомеренең соңгы сәгатьләрендә көрәшерлек бер генә якын кешесе дә калмаган, нәсел тамырлары өзелгән улы Васил, «Сәйдә, сиерчык һәм яз» хикәясендә болай да хәерче, ач халыкны интектергән налоглар, «Меңнәрнең берсе» әсәрендә сугыш кырында әсирлеккә төшеп, ГУЛАГ җәһәннәмнәрендә хаксызга газапланган Зиннур, халык дошманының хатыны буларак эштән эшкә куылган Рабига һ.б. бик күп образлар тулаем ил кичергән фаҗигаләрне гәүдәләндерә. Әлеге әсәрләрдә укучыга үз сүзен әйтергә өлгергән киң карашлы автор образы чагылыш таба. Шунысы үзенчәлекле: авторның иҗтимагый-сәяси карашлары чаң кагып шаулауга исәп тотмый, алар әхлакый проблемалар белән табигый рәвештә керешеп китә.

Алда искә алынган «Тыкрык» повесте мондый сүзләр белән тәмамлана: «Җир шарыдай гәрәбә мәрҗәнне җылы учыма кыстым». Безнең карашка, пычрактан аралап, ап-ак кульяулык белән пакьләнгән сары гәрәбә мәрҗән – бик тирән мәгънәгә ия деталь.Ул – бүгенге болганчык кырыс шартларда кешеләр күңеленә җылылык, өмет өләшүче сүз сәнгатенең, аерым алганда, Гүзәл Әдһәм иҗатының символы.

Лилия КАШАПОВА.

Муса Чахархан Чахоровский (1953) – шагыйрь, журналист, тәрҗемәче. Польшаның Вроцлав шәһәрендә поляк татарлары гаиләсендә дөньяга килә. Поляк телендә дөнья күрә торган «Przeglad Tatarski» («Татар күзәтүе») иҗтимагый-мәдәни журналының баш мөхәррире. 16 шигырь китабы, Коръәннең поляк теленә соңгы тәрҗемәсе авторы. Шигырьләре хорват, рус, төрек, венгр телләренә тәрҗемә ителгән. Әсәрләре татар телендә беренче тапкыр «Идел» журналында һәм «Безнең гасыр авазы» альманахында (Татарстан китап нәшрияты, 2021) дөнья күрде.

Аннары бия сөте...
Кичен аналар җыр суза,
Озын, сагышлы итеп.
Җырлар – бабайлар телендә,
Сүзләрен беркем белми,
Гүя изге моң эчендә
Күләгәләре бии.
Алар һәрчак мәңге зәңгәр
Күк капусы астында,
Җир, Су, Һава көче белән
Тирбәләләр бер тында.
Аннан этиләр, күтәреп,
Ат сыртына утырта.
Чуалган ялны ике кул,
Бер булып, каты тота.
Җил йотабыз, ашкынабыз,
Йон исе сеңә аңга,
Йөрәкләр бөтенләй ачык –
Дөньяга, алсу таңга.
Җилдерәбез. Үлән шаулый...
Җир чәчрәп кала артта...
Без монда!.. Әйе, без – монда!..
Юртып киләбез атта!..

Муса ЧАХОРОВСКИЙ

Минем гомер – ерак бер ил, Офыкларга җәелгән...

* * *

Тарих өчен олы хәсрәт
Кыюлык нәтиҗәсе.
Төсе югалган зиннәт күк
Батырлар хатирәсе.

Бар үлгәннәр иза чигә –
Чәнечкеле таҗ башта.
Укылыр-укылмас язу
Күренеп китә ташта.
Туктаусыз кан саркып тора,
Дәшә алмый, юк сүзе...
Бу – бакый ил хәтеренең
Атудан калган эзе.

* * *

Мин башка дөньядан инде,
Чит җирдә тудым, үстем.
Җиде ятлар арасында
Елларым буйлап күчтем.
Телләрен яхшы белсәм дә,
Сүзләрнең тирәнлеген
Әле һаман аңлый алмыйм,
Бәлки, бер өйрәнермен.
Иң гади сүзләре белән
Мин читләргә тоташам.
Нәрсәнедер якын итәм
Җан әрнүләрем аша.

Минем гомер – ерак бер ил,
Офыкларга җәелгән.
Анда никтер бар да – сүзсез,
Йозак кебек шәй элгән.

Тиз-тиз шунда омтылам.
Күзләремә күк тула.

* * *

Җир шулкадәр генә:
Вакыт-вакыт
Кылыч озынлыгы тоела.
Мин ваемсыз гына авыр сулыйм,
Сорауларны ялгап уема:
Бу җир йокы өчен генәме соң?
Атлап узар өчен арамы?..
Җирдә атам-бабам шәүләләре,
Безнең тавыш тынган.
Караңгы.
Тәнем буйлап тимер ярчык йөри –
Кылычыннан калган бабамның.

* * *

Мин кайчандыр арган-талган
Диңгез ярын гиздем,
Чәчләремдә аның акрын
Тын алуын сиздем.
Күп мәртәбә карурманда
Йокыга да талдым,
Хуш исле ылыс астында
Таяк булып калдым.
Иксез-чиксез илләр буйлап,
Калаларда йөрдем,
Зәңгәр күкне дә иңләдем,
Метроны да күрдем.
«Мейсен фарфоры»ннан затлы
Ризык та ашадым.
Кайчакта тимер савыттан
Су эчеп яшәдем.
Күкрәк тутырып сулаган
Җитез уч исеннән,
Үбү тәменнән яктырган
Хатын-кыз төсеннән
Әсир булдым, мең кат тудым,
Кайнар утта янып,
Һәм бер нәрсә әйтәм сиңа,
Әйтер сүзем анык:
Мин һичкайчан сиңа баккан
Анаң күзендәге
Сизгерлекнең чиксезлеген
Күрмәдем. Син дәме? –
Иң ерак татар даласы
Күптән үз иткәнне –
Кара чәчле, көләч йөзле
Чып-чын ханбикәне.

* * *

Без булдык; хәзер дә барбыз,
Китәбез дә киләбез,
Чиксез вакыт киңлегендә
Гел үзгәрә бирәбез.
Башкалык һәм... бертуктаусыз
Бертөрлелек – үзгә эш.
Хәтердә, дәвамлылыкта
Һәрчак бара үзгәреш.
Без яшәдек; көн итәбез –
Җан түрендә күргәне.
Хатын-кызлар учак саклый,
Ирендә – дала тәме;
Ат кешнәве, тояк чыңы,
Бөркет канат кагышы...
Ишетәсеңме, и Тәңре,
Безнең оран тавышын:
Без – татарлар!
Дөнья буйлап
Тузан туздырып үтик...
Кайда гына башны куйыйк,
Кайсы өндә ял итик?
Җилдерәбез. Үлән шаулый...
Җир чәчрәп кала артта...
Без монда!.. Әйе, без монда!..
Юртып киләбез атта!..

* * *

Ооооуууу-Аааа! Ооооуууу-Аааа!
Ооооуууу-Аааа!
Чакырам сине, Әнием Болан,
Чакырам сине, Әтием Бүре,
Вакыт чоңгылы, онтылган мирас
Тирәнлегеннән килегез бире.
Сез мине моннан алып китегез,
Эз күрсәтегез, кайда булсам да –
Далалар аша ерак-еракка
Хыял йокысы җәелгән анда.
Тамырларымда нинди кан ага? –
Әйтегез, әйдә, туры, дөресен.
Тормышта мине ни-нәрсә тота? –
Дәвамчанлыкның тамыры ныклы…
Тоташ шәүләләр… бармы тересе?
Бәлки, йөрәкне, күкрәктән йолып,
Тын бөркетләргә ташлау кирәктер?
Теткәләсеннәр, чукып, кинәнеп,
Бу бары минем утлы йөрәктер.
Шунда йөрәктә күпме тугрылык,
Күпме җәрәхәт барын тоярлар…
Ә күзләремне, әйе, күзләрне
Чокып алудан кемнәр тыярлар?.
Аларны, бәлки, хөр лачыннарга
Бирү кирәктер? Шунда узганны
Күрә алырмын. Ниһаять, килер
Тоюы билгесез булып торганны.
Әй, Тәңрем, мине яндыр да, әйдә,
Көлемне яңгыр һәм җил таратыр.
Ашкынган атлар таптап узарлар…
Әй, чиксез вакыт, алга бара тор!

* * *

Инде өч тулды, мин һаман
Йоклый алмыйм төн ката.
Эт шикелле аруларым
Мендәр өстендә ята.

Шкаф – дивар арасында –
Шул киңлекнең кисәген
Ашаргамы исәбе?

* * *

Үтенәмен,
и су-анам, чиста суым,
кочакла бер,
ял итимче, гамем юып.

Сеңлем атлар алып килер,
туйганчы эчәрләр.

Үтенәмен,
дала-атам, мәңгелегем,
коткар мине,
кыргый үлән үссен димен.

Сеңлем атлар алып килер,
туйганчы ашарлар.

* * *

Чиксез далада туганбыз
Бүре баласы кебек,
Кан тартуы бик сизелми –
Алда буласы кебек.
Әниләрдән – сарык ите,

* * *

Кичә төнлә
бабам килде,
сүзсез торды.
Күзләре пыяла иде.

Ул күзләрдән
бер йорт карый,
ап-ак дивар...
Өй каршында – карт һәм сабый.

Шул йорт ялгыз
басып калды,
ал офыкка
күләгәсе озынайды.

Һәм, ниһаять,
шыр ялангач
туган нигез.
Җиргә сеңдек өй артыннан, –
гүя агач.

* * *

Күзләрем, минем күзләрем,
сез мине күрәсезме?
Сездән өстә – зәп-зәңгәр күк,
ә аста – бары дала.
Мин үләндә йоклап ятам,
үзгәрешсез манзара
Хәтеремне төшләндерә.
Күк кала, дала кала...
Мәңгеллыклар, дөньяларны
нур булып кисеп узам,
Беркем күрмәгәнне күрәм,
шәүләләргә сүз дәшәм.
Мин тоям. Хәзер җан белән
ал таңны якынайтам...
Бөркет канатлары бара
рухым белән янәшә.
Шуларда очып китик без,
ат ялларын кушучлап,
Ерак тарафка чаптырыйк,
мәгърур Кояшка тикле!
Әй, Тәңре, галәмнәрне ач,
Ач безгә мәңгелекне!

Ленар ШӘЕХ тәрҗемәләре.

Татар җайдакларына

1812 елгы Ватан сугышы башлануга 210 ел

Әле генә Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгын билгеләп үттек. Бу Җиңүне зурлап уздырырга бер дә онытмыйбыз. Ләкин тарихта 1812 елда башланган тәүге Ватан сугышы да булган бит әле. Анда да безнең бабайлар катнашкан, хәтта бик күбесе 1814 елда Париж каласын яулап, татар милләтен дә данга күмгән. Әмма, ни галәмәт, республикабызда әлеге сугыш һәм ерак бабаларыбызның каһарманлыгына багышлап куелган бер генә һәйкәл дә юк.

● «Башкортлар» Гамбург читендәге хәрабәләр янында. 1812 ел. К.Зур.

● С.С.Петров. Касыйм түрә - Касыйм Морза углы (1778 -1813), сотник.

Дәһшәте белән Бөек Ватан сугышыннан ким булмаган коточкыч яу турында гомумән аз беләбез. 1812 елгы сугышта башкорт җайдаклары да катнашкан, алар Парижны яулауда үтә каһарманлык күрсәткән, дигән мактану сүзләрен гаять күп ишеттек. Аларда бу темага багышланган әллә никадәр китап басылды, Уфаның үзендә генә түгел, хәтта үзәктән иң ерактагы Сибай каласында да атлы сугышчылар һәйкәле калкып чыкты. Ул «башкорт» полклары составында меңәрләгән татар җайдаклары да катнашуы турында күкрәк сугарга һаман җыенмыйлар. Шуңа күрә бүгенге Башкортстандагы 1000 нән артык татар авылларыннан түгел, үзебезнең Татарстандагы фәкать Актаныш районыннан 1812 елгы сугышта катнашкан һәм үзебезгә мәгълүм татар җайдакларын санап күрсәтергә булдык. Исемлек, әлбәттә, тулысынча түгел. Әмма республика җитәкчеләрен әлеге бабаларыбызны искә алырга һәм алар истәлегенә махсус һәйкәлләр куярга да этәргеч бирми калмас. Шулай өметләник...

1812 елның 24 июнендә Наполеон Бонапарт кул астындагы француз гаскәре Россиягә бәреп кергәннән һәм рус армиясе Неман елгасыннан алып Смоленск каласына чаклы чигенергә мәҗбүр булганнан соң, 8 август көнне, Россия императоры Александр I башкорт һәм мишәр җайдакларыннан хасил казак полклары оештырырга фәрман бирә. Россиянең көнбатыш чикләренә ул елларда составына Уфа провинциясенең Минзәлә өязе дә кергән Оренбург губернасыннан һәркайсы 500 җайдактан торган 20 полк озатыла. Шул полкларны тәшкил иткән 10 мең «башкорт» яугире белән регуляр армиянең кадровый офицерлары җитәкчелек итә. «Башкортныкы» булып саналган 3 нче, 5 нче, 6 нчы, 19 нчы һәм 20 нче полклар Минзәлә төбәгендә урнашкан авыллардан туплана.

11 нче хәрби кантон составындагы 6 нчы атлы полкны тулысынча Минзәлә өязендәге «башкорт» авылларының яугирләре тәшкил итә. Полк башлыгы – Казан гарнизон полкы майоры Н.Ф.Шайдаров. 21 сентябрьдә полк походка чыга һәм Алабуга, Арча, Казан, Зөя, Чабаксар калалары аша 16 октябрьдә Түбән Новгородка барып җитә. 1812 елның 30 октябрендә ул Балахнаны үтә һәм 24 декабрьдә Устюжня каласына керә. Падишаһ фәрманы буенча, полк бер ел буе Санкт-Петербург белән Вологда арасын саклап тора. Аннары полк җайдаклары Витебск каласында атлы полиция бурычларын үти. 1814 елның 1 апрелендә аны Борисов каласына каравыл хезмәтен алып бару өчен күчерәләр.

10 нчы, 11 нче һәм 12 нче хәрби кантон «башкортлары»ннан оештырылган 5 нче атлы полк Бөгелмә өязенең Карабаян авылында формалаштырыла. Ул походка 25 июль көнне кузгала һәм Чистай, Казан, Зөя, Чабаксарны үтеп, 29 августта Түбән Новгородка җитә. Командиры – Югары Уральскидагы гарнизон капитаны И.Г.Тихановский. 15 октябрьдә полк кенәз П.М.Волконский җитәкчелегендәге отрядка кушыла. Витгенштейн һәм Винценгероде командалыгындагы корпуслар белән берлектә алар Торопец, Белый, Сычевка калаларын Смоленск ягыннан янаучы дошман гаскәре һөҗүменнән саклый. 5 нче «башкорт» полкындагы өч йөз сугышчыны – Велиж, ә калган ике йөзен Сураж каласына урнаштыралар. Шуннан торып разъездлар (атлы төркемнәр) Витебск һәм Рудня калаларыннан килгән юлларны саклап тора.

1812 елның 1 ноябрендә 5 нче полк генерал-майор М.М.Свечин отрядына кертелә, ә бу отряд үзе Витгенштейн корпусының авангардын тәшкил итә. 14-16 ноябрьдә полк җайдаклары генерал Властов отряды составында Березина елгасы янындагы яуларда катнаша. 1812 елның 27 ноябрендә полкның фактта гы башлыгы, гаскәри старшина Ибраһим Бикчурин 3 нче дәрәҗәдәге Изге Анна ордены белән бүләкләнә. Березина янындагы яулардан соң 5 нче полк әсирлеккә төшкән французларны озату өчен Витебск каласына җибәрелә, аннары Борисов каласында тәртип саклау белән шөгыльләнә. Соңрак полк Данциг каласын камалышка алуда катнаша. Аннары 1814 елның апреленә кадәр Минск губернасында җирле полициягә ярдәм күрсәтә, француз әсирләрен һәм яңа гына армиягә чакырылган рекрут партияләрен озатып йөри.

Тагын бер өстәмә кертик. Висла елгасының Балтыйк диңгезенә койган тамагында урнашкан Данциг крепостен генерал Витгенштейн корпусы 1813 елның гыйнвар аенда ук штурмлый башлый. Корпус составында Беренче «башкорт» полкы җайдаклары да була, алар яуларда да катнаша, әмма крепостьны яулауга ирешмиләр. Апрель аенда рус корпусына ярдәмгә Бишенче «башкорт» һәм Икенче типтәр полклары да килеп кушыла, май аенда крепость тулысынча камалышка алына. Ләкин крепостьны 1813 елның декабрендә генә, янә өстәмә рус гаскәре һәм 7 нче «башкорт» полкы килеп җиткәннән соң гына яулауга ирешәләр. Бүгенге башкорт «галимнәре» 2 нче типтәр полкын ялгыш та телгә алмый. Әмма ул типтәр полкы составында туган авылым Байсардан да 95 ир-ат исәптә торган бит. Башкорт «галимнәренә» дәшми калу отышлы, чөнки ул полктагы сугышчылар үзләрен ачыктан-ачык типтәр һәм татар дип атаган, монда «башкорт» борынын йә ярлыгын тыгарлык та түгел. Башкорт «галимнәре» фәкать бер максат – Минзәлә өязендәге «башкорт катламына» язылган ирләре булган татар авылларына «башкорт» ярлыгы сугу өчен эшли. Алар 1812 елгы Ватан сугышында яу йөргән дистәләгән татар каһарманының көмеш медальләр белән бүләкләнүе турындагы хакыйкатьне яшерә. Димәк, Минзәлә өязе җайдакларын курку белмәс, чая итеп күрсәтәселәре килми, дөресрәге – аларның «ысын башкорт» булуына үзләре дә ышанып бетә алмый.

Икенче типтәр полкының бер өлеше әле 1812 елның ноябрь аенда ук гаскәри старшина И.Бикчурин җитәкчелегендә үзәк армия карамагына, инфантерия генералы Барклай де Толлины саклау өчен озатылган була. Шушы эскадроннар Германиядәге Лейпциг каласы янындагы данлыклы яуда катнаша. 4-6 октябрьдә булган бәрелешләрдә күрсәткән каһарманлыгы өчен И.Бикчурин – подпоручик, ә Тукай районының Оргыды авылыннан әүвәл йөзбашы, аннары гаскәри старшина булып йөргән Идрис Сөешев 14 нче класстагы түрә дәрәҗәсе белән бүләкләнә. Ирконәш авылы (бүгенге Минзәлә районында) старшинасы И.Бикчурин һәм аның уллары Габделкаһир белән Габделхалик соңыннан дворян, яки морза исеменә лаек була һәм аның шәҗәрәсе Оренбург губернасының дворяннар китабына кертелә. Полк сугышны Париж каласын яулап тәмамлый.

Хәзер без Актаныш районы авылларыннан Наполеонга каршы 1805-1807 еллардагы кампания, 1812 елгы Ватан сугышы һәм 1813-1814 елларда чит илләрдәге походта катнашкан сугышчылар исемлеген китерәбез.

Актаныш районыннан 11 нче «башкорт» кантонына түбәндәге хәрби йорттүбәләр кергән:

1 нче йорт – Бүләр волостеннан Байсар, Мәчти (1974 елда юкка чыкты), Сәфәр, Олы Имән, Яхшый авыллары;

2 нче йорт – Байлар волостеннан Куҗәкә, Чиргү, Әтәс, Апач;

3 нче йорт – Байлар волостеннан Әҗмәт (Актаныш районының Такталачык авылы янәшәсендә);

6 нчы йорт – Байлар волостеннан Чат, Чынык, Бикчәнтәй, Усы, Адай, Түбән Уръяды, Карач, Измелково (Изменково – Шәбез елгасы буенда яшәгән, юкка чыккан), Каен Түбә (Татар Әҗбие);

9 нчы йорт – Гәрәй волостеннан Такталачык, Түмерҗә (Тайморза), Түбән Такталачык, Теләкәй, Бурсык;

10 нчы йорт – Гәрәй волостеннан Әҗәкүл, Куян, Шәрип, Уразай, Ирмәш;

11 нче йорт – Гәрәй волостеннан Чөгәнә, Югары Актанышбаш, Яңа Актанышбаш, Илчебай, Югары Мерәс, Тыңламас;

12 нче йорт – Йәнәй волостеннан Яңа Богады, Иске Богады, Кадермәт, Солтангол, Ахун, Меңнәр, Елан;

13 нче йорт – Йәнәй волостеннан Чалманарат, Шәбез, Калмаш, Суыксу, Карт;

14 нче йорт – Гәрәй волостеннан Иске Гәрәй, Яңа Гәрәй, Ямалы, Буазкүл (соңрак Өшәр белән кушылган), Кормаш, Балтач, Җияш;

15 нче йорт – Йәнәй волостеннан Өшәр

Һәйкәл кирәк!

● Төньяк амурлары. 2011 ел. Вәгыйз Шәйхетдинов эше.

●Әсирлеккә төшкән французлар «башкортлар» белән калмыклар сагы астында. Р.Кистель.

(Семиостров), Яңа Өшәр, Сәүз (1800 елларда Яңа Өшәрдән бүленеп чыккан), Әҗби;

16 нчы йорт – Табанлыкүл, Чуракай, Әгъбәс;

17 нче йорт – Бүләр волостеннан Зөбәер, Түке, Качкын, Колын;

18 нче йорт – Айман (Иске Айман), Әнәк;

22 нче йорт – Кыргыз волостеннан Аеш, Кадыкай (Кәзкәй), Яңа Әлем, Иске Әлем, Аккүз.

Наполеонга каршы 1805-1807 еллардагы кампаниядә катнашучылар:

1. Походтагы йөзбашы Габделхалик Шәрип углы Айдаров – 1805 елда 25 яшьтә булган, Мәчти авылыннан. 1807 елда 3 нче «башкорт» полкы составында француз гаскәрләренә каршы походта һәм яуларда катнаша.

2. Дистанция башлыгы, йөзбашы Батырша Шәрип улы Шәрипов – 30 яшьтә, Чүри авылыннан. 1807 елда 19 нчы «башкорт» полкы составында француз гаскәрләренә каршы походта була.

3. Гаскәри хорунжий Гали Атнагол улы Чүриев – 31 яшьтә, Әтәс авылыннан. 1807 елда хәрби походларда була.

4.Зауряд-есаул Зөбәер Өметбай улы Мәчтиев – 23 яшьтә, Чынык авылыннан. 1807 елда 19 нчы полк белән походларда катнаша.

5. Йорт старшинасы, зауряд-есаул Әхтәри Мөгътәсар улы Хөсәенов – 19 яшьтә, Солтангол авылыннан. 1807 елда французларга каршы походта, 1812-1814 елларда 19 нчы «башкорт» полкы белән яуларда катнаша, 1812 ел истәлегенә көмеш медаль белән бүләкләнә.

6. Зауряд-хорунжий Туйхуҗа Тойгын улы Барысов – 20 яшьтә, Кадермәт авылыннан. 1807 елгы походларда катнаша.

7. Зауряд-есаул Габдрәшит Әбсәлам улы Айтуганов – 21 яшьтә, Чалманарат авылыннан. 1807 елгы походларда катнаша.

8. Йорт старшинасы һәм гаскәри старшина Хөсәен Акай улы Зөбәеров – 21 яшьтә, Зөбәердән. 1807 елгы походларда була һәм французлар белән яуларда катнаша. 1812 ел истәлегенә булдырылган көмеш медаль белән бүләкләнә.

9. Старшина ярдәмчесе, зауряд-йөзбашы Шәнгәрәй Акай улы Зөбәеров – 17 яшьтә, Зөбәердән (күрәсең, ул Хөсәеннең энесе булгандыр; ә аларга бабай тиеш Зөбәер картны хәзерге Актаныш районында үз исемендәге авылны нигезләүче дип санарга кирәк). 1807 елда 3 нче «башкорт» полкы составында походта була һәм яуларда катнаша. 1812 ел истәлегенә булдырылган көмеш медаль белән бүләкләнә.

10. Йорт старшинасы, зауряд-есаул Ардуан Гадел улы Яугилдин – 19 яшьтә, Аеш авылыннан. 1807 елда 19 нчы полк белән походларда була.

11. Гаскәри старшина Зөбәер Мөҗәй (Мөҗәһит) улы Әбсәламов – 22 яшьтә, Иске Әлемнән. 1812 елда 19 нчы «башкорт» полкы составында сугыша, 1812 ел истәлегенә булдырылган көмеш медаль белән бүләкләнә.

12. Зауряд-йөзбашы Бикташ Габделкадыйм улы Ишмәтов (Ишмөхәммәтов) – 28 яшьтә, Яңа Әлемнән. 1807 елда 20 нче полк белән походларда була.

1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813-1814 елларда Европа походында катнашучылар:

Беренче йорт:

1.14 нче класслы походтагы старшина Габделмәннәф Сөеш улы Сарбулатов (мөгаен, Сарыйбулатовтыр; «сарый» сүзе «бәхетле» дигән төшенчәне аңлаткан) – 26 яшьтә, Олы Имәннән. 1812-1814 елларда 5 нче «башкорт» полкы белән төп армия составында французларга каршы яуларда һәм чит ил походларында катнаша. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә. 1834 елда аңа офицер һәм дворян дәрәҗәләре бирелә.

2.Зауряд-йөзбашы Корбангали Бикташ улы Туктаров – 20 яшьтә, Сәфәрдән. 1812-1814 елларда төп армиядә 6 нчы «башкорт» полкы составында барча походларда була, яулардагы каһарманлыгы өчен 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

3. Зауряд-хорунжий Габидулла Мөсәгыйт улы Миндәев – 20 яшьтә, Байсардан. 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армия белән походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

4. Габделгаффар Бикташев – 29 яшь, Сәфәрдән. 1814 елда армиядә.

5. Мөрсәлим Сәлимҗанов – 28 яшь, Сәфәрдән. 1814 елда армиядә.

6. Габделвәли Габделмаликов – 26 яшь, Сәфәрдән. 1814 елда армиядә.

7. Исмәгыйл Исламгулов – 26 яшь, Олы Имәннән. 1814 елда армиядә.

8. Ямангол Нәҗәргулов – 27 яшь, Олы Имәннән. 1814 елда армиядә.

9. Әрдәшир Идрисов – 28 яшь, Яхшыйдан. 1814 елда армиядә.

Икенче йорт:

10. Йорт старшинасы, зауряд-йөзбашы Габделнасыйр Күзәш улы Чүриев – 23 яшьтә, Чүри авылыннан (бабасы Чүри үз исемендәге авылны нигезләгән). 1812-1814 елларда 6 нчы «башкорт» полкы белән барча походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

11. Зауряд-хорунжий Хәйбулла Ишкилде улы Шигаев (Шыгаев-?) – 24 яшьтә, Мәчти авылыннан. 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армиядә була, Европа походларында һәм яуларда катнаша. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

12. Зауряд-хорунжий Шәмсетдин Сагындык улы Сөләйманов – 25 яшьтә, Куҗәкә авылыннан. 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армиядә, хәрби походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

13. Хисаметдин Мөрсәлимов – 31 яшьтә, Әтәс авылыннан. 1814 елда армиядә була.

14. Гаскәри старшина Габдессәлам Габдрәшитов – 19 яшьтә, Куҗәкәдән. Кайсы полкта яу йөрүе билгеле түгел, әмма 14 нче класслы түрә һәм дворян дәрәҗәсе белән бүләкләнүе мәгълүм.

15. Мөхәммәтгали Батырша улы Шәрипов – Куҗәкәдән. 1813 елда армиядә.

Алтынчы йорт:

16. Старшина ярдәмчесе, зауряд-йөзбашы Имәнгол Мөхәммәтрәхим улы Мөслимов – 20 яшьтә, Чат авылыннан. 1812-1814 елларда 6 нчы «башкорт» полкы составында төп армиядә һәм походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

17. Зауряд-йөзбашы Гайнулла Мәсәгут улы Сәйтәков – 24 яшьтә, Бикчәнтәй авылыннан. 1807 елда – 19 нчы «башкорт» полкы, ә 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында хәрби походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

18. Зауряд-йөзбашы Ногманнасыйр Мәдияр улы Бикчурин – 30 яшьтә, Бикчәнтәйдән. 1812-1814 елларда 5 нче «башкорт» полкы составында төп армиядә французларга каршы яуларда сугыша, чит илләрдәге походларда катнаша. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

19. Зауряд-йөзбашы Исламгол Өметбай улы Мәсиев (Мәчтиев-?) – 20 яшьтә, Чынык авылыннан. 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армиядә һәм походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

20. Төхфәтулла Кылычев – 28 яшь, Усы авылыннан. 1812 елда армиядә була.

21. Фәйзулла Габитов – 25 яшь, Усыдан. 1812 елда армиядә.

22. Бәхтияр Мәдияр улы Әитов – Бикчәнтәйдән. 1806-1807 елларда Пруссия кампаниясендә һәм 1812 елда 19 нчы «башкорт» полкы составында сугышкан өчен 1812 ел истәлегенә булдырылган көмеш медаль белән бүләкләнә.

Җиденче йорт:

23. Йорт старшинасы һәм гаскәри старшина Габделлатыйф Әбсәлам (дөресе - Габдессәлам) улы Кормашев – 31 яшьтә, Нөркәй авылыннан (Сарман районында; аның әтисе Габдессәлам әле 1800 елларда ук Актаныштагы Кормаш авылыннан Нөркәйгә күченә, Күктәкә һәм Мусабай Завод авыллары тирәсендә бик күп җирләр били, сәүдә белән шөгыльләнә). 1812-1814 елларда 5 нче «башкорт» полкы составында төп армиядә һәм чит ил походларында катнаша, канлы яуларда каһарманлык күрсәтә. 1812 ел истәлегенә һәм Париж каласын алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

(Дәвамы 11 нче биттә).

Мәдәни җомга
20 май
№19, 2022

Атнаның сәяси мизгелләре

Күмәк киңәшләшү

Гаҗәп хәл, халыкара мөнәсәбәтләрдә сәяси температура кызган саен, аның субъектларында үз тарафдарлары белән күмәк төстә киңәшләшеп алу теләге дә арта бара. Зур сәясәттә андый хәлләр узган атнада да күзәтелде. Сүзне Күмәк иминлек килешүе оешмасына (ОДКБ) кергән илләр (Россия, Беларусь, Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан һәм Әрмәнстан) лидерларының 16 майда Мәскәүдә үткән саммитыннан башлыйк. Рәсми яктан ул берьюлы ике юбилейга – Күмәк иминлек килешүенең 30 еллыгына һәм аның нигезендә төзелгән оешманың 20 еллыгына багышланган иде. Әлбәттә, бу чорда җитди үзгәрешләр халыкара аренада гына түгел, оешманың үзендә дә булды (әйтик, Үзбәкстан аннан инде ике тапкыр чыгып өлгерде һәм бүген дә анда әгъза саналмый). Ә саммитның үзенә килгәндә, аның ачык өлешендә НАТО нык тәнкыйтьләнгән. Әмма эш нәтиҗәләре буенча кабул ителгән махсус белдерүдә, һич көтмәгәндә, Евразиядә киеренкелекне киметү хакына, альянс белән гамәли эш йөртүне җайга салырга оешманың әзер булуы турында әйтелә. Димәк, моңа этәргән сәбәпләр бар. Шуның белән бергә, тарихны бозып күрсәтү, нацизмны геройлаштыру, неонацизм, расачылык һәм ксенофобияне җәелдерү кебек күренешләргә каршы торырга оешманың әзер булуы хакында да уртак фикергә килгәннәр. Украина исә йомгаклау документларында бер мәртәбә дә телгә алынмаган.

Күмәк киңәшләшү чаралары Көнбатышта да булды. Алар Алманиядә үткәрелгән. Баштарак анда «Зур җиделек» (G7) очрашуында Украинага ярдәмне киңәйтү һәм Россиягә карата санкцион басымны көчәйтү мәсьәләләре каралган. Ә 14-15 май көннәрендә инде НАТО илләре тышкы эшләр министрларының Берлинда үткән очрашуында Украинадагы хәлләр һәм Россия белән мөнәсәбәтләрнең киләчәгенә караган мәсьәләләр күтәрелгән. Экспертлар әйтүенчә, әлеге очрашу альянсның 29-30 июнь көннәрендә Мадридта узачак саммиты алдыннан әзерлекне тикшерү чарасы да булып тора. Ә ул очрашуда инде альянсның яңа стратегиясе кабул ителәчәк. Шуңа күрә бу мәсьәлә узган шимбәдә АКШ дәүләт секретаре Энтони Блинкен НАТО җитәкчесе Йенс Столтенберг белән очрашканда да үзәктә торган. Чөнки сүз инде «глобаль НАТО» (Европа-Атлантика иминлеге генә түгел, Һинд-Тын океан төбәге иминлеге өчен дә җаваплы) стратегиясе турында да бара. Алмания тышкы эшләр министры А.Бербок сүзләренә караганда, Россиянең махсус операциясе Көнбатыш өчен моңарчы күрелмәгән янау булып кына калмады, альянс үсешенең яңа этабына этәргеч тә бирде. Финляндия һәм Швецияне НАТОга әгъза итеп алу инде шул юлдагы тәүге сынау адымнары да булачак.

Фоат УРАЗАЙ.

КАЙТ, БӘГЪРЕМ!

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ

(Ахыры. Башы 18 нче санда).

Икенче көнне, беренче таң нурлары белән, аларны районга колхоз аты алып китте. Авыл башына чыгып, иң кадерле кешеләре озатып калды. Әти-әниләре, туганнары, бер читтә – бер-берсенә сыенышып, өч кыз калды...

Егетләр авыл күздән югалганчы кул болгап барды. Бераздан, дилбегә тотып, иртәнге йокысында оеп барган Сафа картка ишетелмәслек итеп, Хәмит әйтеп куйды:

– Бүген таңда без Миңниса белән өйләнештек...

Сәлимгәрәй аңламады.

– Ничек инде? Кайчан? Ә никах, туй?

– Үзебезгә үзебез никах догалары укыдык... Бер-беребезгә шаһит булдык... Кияү белән кәләш кенә түгел, ир белән хатын булдык...

– Без дә өйләнештек. Зифа үзе шулай теләде... – Сүзгә Хисмәт тә кушылды. – Кышка кадәр кайтырбыз дип уйлыйм, чын туйны шунда ясарбыз... Ә син, Сәлимгәрәй? Ә сез өйләнештегезме?

Сәлимгәрәй дәшмәде. Ә егетләр башка сорашмады. Һәркем үз уйлары белән, үз язмышы белән күзгә-күз карашып, ялгызы торып калды...

* * *

Эшелон бара да бара. Авыр ыңгырашып, барыйм микән, юк микән дип бара. Сугыш башланганга өч ай гына, ә ул инде арыган, талчыккан... «Бу халыкны сугыш авызына күпме ташырга була инде?» дигән кебек, теләмичә генә, станцияләрдә туктап-туктап, сугыш афәтенә илтү өчен, берәмләп тә, төркемләп тә авыллардан, шәһәрләрдән халык җыя-җыя бара... Аның болай ашыкмыйча, озаклап баруы Сәлимгәрәйгә ышаныч бирә: ул җибәргән хат Гөлчирәгә алдарак барып җитеп, аны станциягә алып киләчәк...

Ниһаять, халык арасында «Казан» дигән сүз чыкты, димәк, күп калмаган. «Өч-дүрт сәгатьтән» диделәр. Шулай да, Сәлимгәрәй торып утырды, өстен-башын рәтләде, янындагы капчыкны капшап куйды. Анда Гөлчирәсенә кашемир яулык ята. Ул аны, үзенә тиешле шикәр шакмакларын җыеп, бер базарга чыкканда шул шикәргә алмаштырып алган иде. Ул вакытта әле очрашу турында уйлаганы да юк иде. «Сугышта җиңеп кайткач бирермен» дип кенә уйлый иде. Хәзер инде белә: бу сугыштан тиз генә кайтып булмаячак. Шуңа да кирәк аңа бүгенге очрашу, бик кирәк!

Казанны узып киткәч тә шактый бардылар әле. Ниһаять, эшелоннары әле усал пошкырып, әле ачы сызгыртып, бер станция читендәге ялан кыр уртасына килеп туктады. Ярты сәгатьләп чыгармый тордылар. Шуннан соң гына, шалтыр-шолтыр килеп, тышкы яктан ишек бикләрен күтәрә башладылар... Ишекләр ике якка этелеп ачыла башлауга ук якты көнгә, кояш яктысына тансыклаган хәрбиләр җиргә коелды...

Сәлимгәрәй шунда ук Мансурны эзләп тапты. Гади солдатларны станциягә якын җибәрмиләр. Ә менә ул бара ала, сораша ала. Станция буйлап берәрсе эзләп йөрмиме?

Мансур әйбәт сөйләште. Бераз эшләрен җайлагач, барып килергә булды. Болай да аның станция башлыгына кереп чыгасы бар икән...

– Хәзергә үз урыныңа барып тор. Югыйсә югалтырлар, качкынга санап, тавыш күтәрерләр. Берәр яңалык булса, үзем эзләп табармын. Бар, бу якта артыгын сорашып, кирәкмәгән җиргә тыкшынып йөрмә... Юкса... «красноперыйлар» шикләнә башлар... Бар... Тукта! Сөйгән кызыңның исеме ничек соң? Гөлчирә? Матур исем. Минем әнкәйнең исеме. Дөресе – Гөлчәһрә. Гөл йөзле, чәчәк йөзле дигәнне белдерә...

Эшелон дүрт сәгать тора икән, шуның бер сәгате үтеп тә китте... Сәлимгәрәй үзен кая куярга белмәде. Юньләп тамагына да капмады, дуслары, хезмәттәшләре белән дә аралашмады. Күзләрен эшелонның станция ягындагы очыннан алмады. Мансур һаман күренмәде. Кемдер гармун шыңшыта башлады, кемдер аңлашылмаган телдә җыр сузды... Ул арада эшелонга берничә вагон тактылар, аларга үз аяклары белән килгән берничә колонна хәрби кереп тулды. Сәлимгәрәй шулар арасында Мансурны күреп алды. Шундук аның янына йөгерде. Мансур, «шунда гына тор, бераздан үзем киләм» дигән ишарә белән, сабыр итәргә кушты. Чынлап та, Сәлимгәрәй кая барып бәрелергә белми торганда, Мансур килеп тә җитте.

– Әйдә!

– Кая? Таптыңмы, күрдеңме минем Гөлчирәне?

– Гөлчәһрәнеме?.. – Үзе кайтарып сораган була, үзе мут елмая...

– Кемне булсын?! Аны инде, Гөлчирәне!

– Әйдә! Ә-нә, күрәсеңме поход кухнясын? Шуның яныннан барып табарсың. Авылдан бирле йөгереп, тәмам талчыккан, мескенкәй... Җитмәсә, камерага кертеп япканнар үзен. Документлары да юк... Уйлап кара: бер документсыз кеше хәрби эшелон эзләп йөрсен инде, ә?! Ярый әле атып үтермәгәннәр... Ну авыл гыйбады!..

Сәлимгәрәй поход кухнясына таба йөгерде, Гөлчирәсен шуннан тапты. Кыз кухня баскычында солдат котелогыннан тары боткасы ашап утыра иде.

– Гөлчирә!

– Сәлим!.. – Котелок шалтыр-шолтыр кухня баскычына төшеп китте, кыз, ике кулын алга сузып, Сәлимгәрәйгә таба атылды...

Алар бик озак, бер-берсеннән аерыла алмыйча, кочаклашып тордылар. Яннарына җыела башлаган солдатлар ягыннан төртмәле сүзләр ишетелә башлагач кына айнып киткәндәй булдылар, читкәрәк барып, бөдрәләнеп торган ялгыз куак янынарак барып, рәхәтләнеп үбештеләр...

Бервакыт бөтен дөнья тынып калды. Җир әйләнүдән туктады, җил исми, кошлар очмый, сайрамый башлады. Станциядәге паровозлар да гудок бирүдән туктады, бая шыңшый башлаган гармун да, чит телдә яңгыраган җыр да ишетелмәс булды... Бер-берсен өзелеп сагынган, назга, яшьлек дәртенә тансыклаган ике яшь йөрәк берьюлы эшелон торган тимер юл буена борылып карады... Ә анда... гаҗәп күренеш барлыкка килгән иде: әле бая гына үз-үзләрен кая куярга белмичә, кырын төшеп, гәп куертып яткан яисә эшелон буйлап ары-бире йөгерешкән солдатлар Сәлимгәрәй белән Гөлчирәне божра уртасына алып, аркалары белән, яннарын янга куеп, тыгызланып басканнар, ә шинельләрен, бушлатларын җиргә түшәп, ике гашыйк янәшә басып торган куак читенә «кияү ятагы» ясаганнар... Берничә винтовканы аркылы бастырып, аларны шинельләр белән ябып, куыш кебек нәрсә әмәлләгәннәр. Солдатларның бу эшен иң элек Гөлчирә аңлап алды, Сәлимгәрәйнең кулбашына кулларын куеп, аңа шул куыш алдына чүгәргә кушты... Үзе беренче булып итәк читенә чүгәләде, аннары, йомры, ак тезләрен ачып, куыш эченә сузылды...

* * *

Хәрби составның аргы башында җанлылык барлыкка килде. Бу хатын-кыз тавышы белән бәйле иде. Бу тавыш кемнедер сорый, хәтта таләп итә иде:

– Беләм, шушы поездда ул. Миңа үзе шылтыратты. Дүрт сәгать торабыз, диде. Аны күрер өчен сигез чакрым йөгереп килдем. Барыбер күрмичә китмим, командир иптәш, табарга булышыгыз минем Мансурны, ә?!

Әнә алар бу таба киләләр. Озын итәкле күлмәк кигән, кулына яулыгын тоткан, чәчләрен җилбәгәй җибәргән, ашыгудан йөзләре алсуланып янып чыккан кыз белән беләгенә кызыл тасма бәйләнгән карт майор. Майор дәшми, ул кая, кемгә төбәп килгәнен белә булса кирәк, ә кыз һаман тынычлана алмый, кемнедер таптырыпмы таптыра:

– Табыгыз инде, ә, командир иптәш! Яратам бит мин аны, күрмичә китә алмыйм...

– Саматов! Саматов, син кайда?

Саматов дигәннәре баягы егетләрнең Мансур исемлесе булып чыкты. Менә алар – ике яшь йөрәк – атлап түгел, хәтта йөгереп тә түгел, очып килде дә бер-берсенең кочагына атылды. Аннары, билләреннән тотышып, якындагы куаклыкка таба юнәлделәр. Карт майор, бер-берсенә сыенышып барган бәхетле яшьләр ягына карап, чал чәчле башын чайкап куйды да үз эше белән китеп барды.

Август, 2021

(Дәвамы. Башы 8 нче биттә).

Тугызынчы йорт:
24. Зауряд-йөзбашы Габделсаттар Габделлатыйф улы Гомәров – 25 яшьтә, Такталачык авылыннан. 1807 елда – 3 нче «башкорт» полкы, 1812-1814 елларда 5 нче полк составында походларда һәм яуларда катнаша, 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
25. Гобәйдулла Зөлкәрнәев – 29 яшьтә, Югары Такталачыктан. 1812 елда армиядә була.
Унынчы йорт:
26. Зауряд-есаул Габделмоталлап Габделкәрим улы Исәнбаев – 27 яшьтә, Уразай авылыннан. 1812-1814 елларда 5 нче полк составында французларга каршы яуларда һәм чит ил походларында катнаша, каһарманлыгы өчен 1812 ел истәлегенә булдырылган көмеш медаль белән бүләкләнә.
27. Ибраһим Ильясов – 31 яшьтә, Әҗәкүлдән. 1812 елда армиядә була.
28. Хәбибулла Гаделшин – 25 яшь, Әҗәкүлдән. 1812 елда армиядә.
29. Габделваһап Сөендеков – 31 яшь, Куян авылыннан. 1812 елда армиядә.
30.Габделлатыйф Габитов – 30 яшь, Уразайдан. 1812 елда армиядә.
31. Габделмәҗит Габдуллов – 27 яшь, Уразайдан. 1812 елда армиядә.
32. Мөхәммәтша Батыршин – 28 яшьтә, Ирмәш авылыннан. 1812 елда армиядә.
33. Кадергол Туишев – 30 яшьтә, Шәриптән. 1812 елда армиядә була.
Унберенче йорт:
34. Зауряд-йөзбашы Котлыяр Яркәй улы Аканов (?) – 22 яшьтә, Мерәс авылыннан. 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә
35. Габделшәрип Монасыйпов – 30 яшь, Югары Актанышбаш авылыннан. 1812 елда армиядә була.
36. Искәндәр Ишмәнов – 30 яшьтә, Тыңламас авылыннан. 1814 елда армиядә.
37. Биктимер Юлдашев – 29 яшь, Тыңламастан. 1813 елда армиядә.
Уникенче йорт:
38. Фазулла Һидаин – 36 яшьтә, Яңа Богадыдан. 1812 елда армиядә була.
39. Габделнасыйр Рәфыйков – 33 яшь, Яңа Богадыдан. 1814 елда армиядә.
40. Габделтаһир Габделҗәлилов – 27 яшь, Иске Богадыдан. 1813 елда армиядә.
41. Габделхәбир Дәүләтбаев – 28 яшь, Кадермәттән. 1812 елда армиядә була.
42. Габделвахит Габделкәримов – 27 яшь, Кадермәттән. 1812 елда армиядә.
43. Габделбәшир Аднагулов – 27 яшь, Кадермәттән. 1812 елда армиядә.
44. Габделшәриф Йөзекәев – 28 яшь, Солтанголдан. 1812 елда армиядә була.
45. Әлби (Галибай) Вәлитов – 27 яшьтә, Солтанголдан. 1813 елда армиядә.
46. Сөләйман Сабитов – 23 яшьтә, Солтанголдан. 1814 елда армиядә.
Унөченче йорт:
47. Зауряд-йөзбашы Габделкадыйр Миңлебай улы Канбаров (Хәмбәров-?) – 20 яшьтә, Карт авылыннан. 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армиядә һәм чит илләргә походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
48. Зауряд-хорунжий Миңлегол Котлымәт (Котлыгмөхәммәт) улы Канбаров – 26 яшьтә, Суыксу авылыннан (боларның бабасы бер үк кеше булу мөмкин). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армиядә һәм чит илләргә походларда була.



● «Башкорт» кавалеристлары Парижда. 2011 ел. И.Бикбулатов, Т.Мәсәлимов.

Татар җайдакларына һәйкәл кирәк!

1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
49. Урядник Фәтхулла Ильясов – 18 яшьтә, Суыксудан. 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армиядә һәм чит илләргә походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
50. Мөхәммәтрәхим Мөсәгыйтов – 30 яшь, Шәбездән. 1813 елда армиядә.
51. Бикташ Миндәшев – 28 яшь, Шәбездән. 1812 елда армиядә була.
Ундүртенче йорт:
52. Йорт старшинасы, зауряд-хорунжий Хәйбулла Ильяс улы Иләмәнев – 20 яшьтә, Җияштән. 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армиядә һәм чит илләргә булган походларда була, каһарманлыгы өчен 1812 ел һәм Парижны алу истәлегенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
53. Зауряд-есаул Габделгалим Габдекәй улы Теләкәев – 25 яшьтә, Иске Гәрәй авылыннан. 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армиядә һәм чит илләргә походларда катнаша, каһарманлыгы өчен 1812 ел һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
54. Габделкаһир Әбдекәев – 28 яшьтә, Иске Гәрәйдән. 1814 елда армиядә була.
55. Каһарман Тимеркәев – 26 яшьтә, Иске Гәрәйдән. 1814 елда армиядә.
56. Моратбакый Сөендеков – 30 яшь, Җияштән. 1814 елда армиядә.
57. Фәйзулла Сөендеков – 27 яшьтә, Җияштән (соңгы икесенең бертуганнар булуы да мөмкин). 1813 елда армиядә була.
58. Габидулла Яманголов – Иске Кормаш авылыннан. 1812-1814 елларда 5 нче «башкорт» полкы составында яуларда һәм Европага походта катнаша. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
Унбишенче йорт:
59. Зауряд-йөзбашы Нариман Миндәй улы Сар(ый)булатов – 20 яшьтә, Сәүз авылыннан (Иске һәм Яңа Өшәр крестияннары XVIII гасыр азагында Актаныш районында оештырган яңа авыл. 1816 елда анда 120 кеше яшәгән. Хәзер авыл юк инде). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армиядә һәм чит илләргә походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
60. Зауряд-йөзбашы Гаделша Дәүләтбай улы Купаев (?) – 20 яшьтә, Әҗби авылыннан. 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армиядә һәм чит илләргә походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
61. Мәнди Габитов – 28 яшь, Сәүздән. 1814 елда армиядә.
62. Рәхимкол Нәдергулов – 28 яшьтә, Әҗбидән. 1814 елда армиядә була.
Уналтынчы йорт:
63.Төхфәтулла Фәйзуллин – 36 яшьтә, Табанлыкүл авылыннан. 1813 елда армиядә була.
64. Ардуан Рәфыйков – 27 яшь, Әгъбәс авылыннан. 1813 елда армиядә.
65. Әхтәм Ихсанов – 27 яшь, Әгъбәстән. 1813 елда армиядә.
Унҗиденче йорт:
66. Зауряд-есаул Ногъман Хәмит улы Туйкин – 22 яшьтә, Түке авылыннан. 1812-1814 елларда 5 нче «башкорт» полкы составында төп армиядә һәм чит илләргә походларда була, яулардагы каһарманлыгы өчен 1812 ел һәм Парижны алу истәлегенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
67.Гайнулла Килдеяров – 28 яшь, Зөбәер авылыннан. 1814 елда армиядә.
68. Гайнулла Тукаев – 29 яшьтә, Зөбәердән. 1814 елда армиядә.
Унсигезенче йорт:
69. Старшина ярдәмчесе Ибраһим Айдагол улы Морзакаев – 22 яшьтә, Айман авылыннан. 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армиядә һәм чит илләргә походларда була, яулардагы каһарманлыгы өчен 1812 ел һәм Парижны алу истәлегенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
70. Габделкадыйр Габитов – 28 яшь, Айманнан. 1812 елда армиядә.
71. Сәйфетдин Мөхәммәтрәхимов – 27 яшь, Айманнан. 1812 елда армиядә.
Егерме икенче йорт:
72. Зауряд-йөзбашы Габделгаффар Габделсәлам улы Ишмәтев – 21 яшь, Яңа Әлем авылыннан. 1807 елда 20 нче «башкорт» полкы, 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армиядә һәм чит илләргә походларда була, каһарманлыгы өчен 1812 ел истәлегенә булдырылган көмеш медаль белән бүләкләнә.
73. Зауряд-йөзбашы Вәлиша Шәрип улы Шәйдәков – Яңа Әлемнән. 1812 елда 20 нче «башкорт» полкы составында походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
74. Хазбулат Сәлимҗанов – 31 яшь, Аештан. 1812 елда армиядә була.
75. Гыйсмәтулла Бикташев – 28 яшь, Аештан. 1813 елда армиядә.
76. Фарукша Арсланов – 30 яшьтә, Яңа Әлемнән. 1812 елда армиядә.
77. Мәндикәй Әбсалихов – 30 яшь, Яңа Әлемнән. 1812 елда армиядә.
78. Ярмөхәммәт Рапталов – 30 яшь, Яңа Әлемнән. 1812 елда армиядә.
79. Габделсаттар Әбҗәлилов – 24 яшь, Яңа Әлемнән. 1812 елда армиядә.
80. Исхак Габделсалихов – 23 яшь, Яңа Әлемнән. 1812 елда армиядә.
81. Иләмән Вәлитов – 30 яшь, Иске Әлемнән. 1812 елда армиядә.
82. Ибраһим Тойгынов – 31 яшь, Аккүз авылыннан. 1812 елда армиядә.
Егерме бишенче йорт:
83. Зауряд-есаул Габделнасыйр Зәйсән улы Имаммәтев – 30 яшь, Теләкәй авылыннан. 1812-1814 елларда 6 нчы полк белән төп армиядә һәм чит илләргә походларда була. 1812 ел истәлегенә һәм Парижны алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.
...1812 елгы яулар һәм походларда Татарстанның Әгерҗе, Сарман, Мөслим, Әлмәт, Минзәлә, Тукай районнарыннан да «башкорт» һәм типтәр полклары составында йөзәрләгән татар җайдаклары катнаша, ни кызганыч, исемнәрен һәм каһарманлыкларын гына искә алучы юк. Бөек Ватан сугышында ил азатлыгы өчен һәлак булган якташларыбызның исемнәре махсус стелаларга язып куелган, алар хөрмәтенә куелган һәйкәлләр санап бетергесез. 1812 елда Наполеон Бонапарт гаскәренә каршы яуларда һәлак булган геройлар да – безнең бабайлар бит. Алар рухы бездән кадер-хөрмәт тә, һәйкәлләр дә сорый.

Вахит ИМАМОВ.

● Игелек.

МИЛЛИ ТӨСМЕРЛӘ

Милләттәшебез Алена Әскәрова Чиләбедә туган һәм бүген дә шушы шәһәрдә яшәп иҗат итә. Чиләбе сынлы сәнгать училищесын уңышлы тәмамлауга ук, Санкт-Петербургның Илья Репин исемендәге сынлы сәнгать академиясе курсларына укырга чакырылган ул. Аленаны Төньяк башкалада калырга өндәүче рәссамнар күп булган, әмма гаилә тормышына өстенлек бирүе сәбәпле, андый тәкъдимнәрдән баш тарткан.

Алена Сәгъдулла кызының картиналары искиткеч популяр! Милләттәшебез үз иҗатында җете төсләргә бай татар милли колоритына таянуын ассызыклый. Милли традицияләребезне, ана телен яхшы белүенә дә чын күңеленнән шат. Ул күбесенчә дәү әтисе һәм дәү әнисе тәрбиясендә үскән һәм аларның уңай йогынтысын һәрчак истә тота. «Әбием Бәдриәфә һәм бабам Җәләлетдин авыр, михнәтле елларда яшәсәләр дә, һәрчак көр күңелле булып, Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылып, намаз укып гомер иттеләр. Җәләлетдин бабам бик укымышлы кеше булды, гарәпчә дә белә иде. Бөек Ватан сугышы елларында тылда, заводта эшләгән, җиңү өчен күп көч түккән тырыш зат иде. Аның зыялылыгы нәсел тарихы белән дә бәйле, чөнки дәү әтиемнең гаиләсе бирегә Владивостоктан күченгән. Бәлкем, репрессияләр аша узган гаилә булгандыр дип фикерлим, чөнки ул кечкенә чагында озак вакытлар поезд вагонында барганын хәтерли иде.

Балачагым шартлары, шул мохиттә күңелемдә туган хис-кичерешләр әле дә хәтеремдә саклана. Мин матурлыкны кечкенәдән бирле тойдым. Әбием Бәдриәфә кул эшләнмәләре остасы иде. Татарча җырлый, арып китсә, эшләнмәләрен куеп, биеп тә ала иде. Сәйлән һәм чигү җепләре белән чигүләр дә чиккән әбием, ачлык котырынган чорда аларны сатып җан асраган... Әби-бабам озын-озак эшләп тә сукранмыйлар иде. Хәзер мин кайчак шул чакларны анализлыйм. Үзем дә кышларын бәйләм бәйлим, киемнәр тегәм. Әнием Бибисафа сатучылык эше белән шөгыльләнде. Ә мин исә балачактан ук гел рәсем ясадым. Шуңа күрә рәссамлык һөнәрен сайлап алуым һич гаҗәп түгел. Санкт-Петербургтагы И.Репин исемендәге сынлы сәнгать академиясе курсларыннан соң Чиләбегә әйләнеп кайттым. Бу халык өчен авыр-болгавыр 1990 еллар иде. Гаилә кордым. Безнең, әлхәмдүлилләһ, ике улыбыз бар! Мин картиналарны һәрчак майлы буяулар белән ясыйм. Һөнәри, хөр рәссам мин. Билгеле, рәссам хатын-кыз белән яшәү бик җиңел түгелдер... Әмма ирем иҗаттан башка яши алмаганымны күптән аңлады инде. Иҗат рәссам өчен сулыш алу белән бер», – диде ихлас әңгәмәдәшем.

А. Әскәрова, вакыт табып, башкалар өчен осталык дәресләре үткәрергә дә, бакча эшләрен алып барырга да җитешә. «Гаиләбезнең матди ягы хәләл җефетем җаваплылыгында, ул – чын татар ир-аты, ышанычлы, үз сүзендә тора белүче. Гаилә мәшәкатьләренең хатын-кызга хас ягы – минем өстә, без үз йортыбыз белән яшибез. Хәзер күпләр сыйфатлы ризыклар гына ашарга тырыша, сәламәтлекне ныгыту, дөрес итеп туклануга без дә бик игътибарлы, шуңа күрә мин дә көн буе иҗатта гына булмыйм...

Өлкән улыбыз үзен Мәскәүдә киноиндустрия өлкәсендә сыный. Кыска метражлы документаль фильмнар төшерә. Аның иҗатчы булуына куанабыз. Төпчек улыбыз – әле мәктәп укучысы.

Совет елларында кыз балаларга Алена дигән исемне еш кушканнар... Менә хәзер Айшә исемен кабул иттем, әлхәмдүлилләһ!

Иҗат темаларыма килгәндә, унбиш еллап портретлар ясаганым юк иде инде... Үзчикләүләр кертелгән елда гына хәләл җефетемнең портретын иҗат итәргә насыйп булды. Ә болай, күбесенчә, анык кемнедер түгел, ә хатын-кызларыбызның гомуми образларын сурәтләүгә өстенлек бирәм. Тик искәрмә һәрчак бар... Әйтик, «Сәйлән» дип аталган картинамда газиз әбиемне сурәтләдем. Ни өчен «Сәйлән»?! Чөнки әбием мәрҗән төсендәге сәйлән белән чикте, изүләрне дә, түбәтәйләрне дә матур итеп бизәде... Үзе һәм башкалар өчен дә... Шул чигүләре әле дә истә.

Гомумән, киндерләремдәге образларым – метафоралар да. Аларны җан образы дисәм, төгәлрәк тә булыр. Мин җан үсеше мөһимлегенә игътибар итәм. Шуңа күрә дә бу хакта һәрчак искәртәм, әйтик, 2021 елда ачылган шәхси күргәзмәмне дә «Җан төсе» дип атадым. Үзем дә дин белән бәйле әдәбиятны күбрәк укый башладым. Суфыйлык, шәрык фәлсәфәсе белән бәйле әдәбиятны ошатам, Җәләлетдин Руми иҗатына игътибар юнәлттем.

●Энҗе эзләүче.

Хатын-кыз һәм балалар образларым күпләрнең күңел түренә барып ирешә, күпләрне җәлеп итә! Хатын-кыз ул бит беркайчан да авырлыклар алдында сыгылып төшми, бирешми, ул һәрчак иҗатта. Шушы якты идеяләремне алга сөрәм. Картиналарымны үзенчәлекле дип танып, аларны ошатучылар бар. Әйтик, сәнгать сөючеләр арасыннан Чиләбедәге мәшһүр гаилә – Лена һәм Олег Колесниковлар гаиләсенә мин бик рәхмәтле! Алар үз рәссамнарыбызның, шул исәптән, минем әсәрләремне дә еш сатып ала. Бу күркәм гаилә рәссамнарыбызның әсәрләренә, иҗатларына һәрчак игътибарлы. Бүгенге көндә рәссамнарга булышучы, картиналарын сатып алып, аларны яңа әсәрләр язарга мөмкинлек бирүче меценатлар булуы шулкадәр шәп! Үзләренең дә эш-гамәлләре алга гына барсын!»

Алена Сәгъдулла кызы дизайнерлык өлкәсенә дә үз өлешен кертә. Декоратор буларак, диварлар бизи, интерьер эшләнмәләрен, барельефлы сәнгать әсәрләрен иҗат итә.

Ул 1997 елдан алып – «Инкор» Халыкара ассоциациясе һәм 2003 елдан алып Россия Рәссамнар берлегенең Чиләбе рәссамнары бүлеге әгъзасы. Моннан кала Алена Әскәрова – 1990 елларда төрле милләт һәм төрле конфессиядәге хатын-кыз рәссамнарны берләштергән «Многолетники» яшьләр иҗат төркемен оештыручыларның берсе. «Узган гасыр ахырында хәтта ир-атлар да нык боекты, ничек тормыш итәргә дип еш уйландылар, кайгырдылар... Ә менә хатын-кызлар шул михнәтле, халык иза чиккән елларда да тормышны ничек тә алга алып барырга омтылдылар, һәрчак көчле рухлы булдылар... Безнең төркем дә шул еллардан бирле хатын-кызларга багышланган хезмәтләр иҗат итүгә өстенлек бирә. Күмәк күргәзмәләребезне әле дә ачып торабыз», – диде оста.

Рәссам ханымның хезмәтләре

●Зур энә карагы.

●Кар яву.

СӘНГАТЬ

●Энҗе йөртүче.

●Дәрвиш.

1996 елдан башлап бихисап төбәкара, Бөтенроссия, халыкара күргәзмәләрдә экспозицияләнә. Ул инде сигез шәхси күргәзмәсен ачкан һәм аларның һәммәсе олуг уңыш белән барган. Чиләбе өлкәсе татарлары оештырган зур мәдәни чараларда катнашкан һәм мондый форумнарга җыелган халык милли төсмерле әсәрләрне кат-кат карап, сокланган.

Рәссамыбыз Чиләбе өлкәсендә узып торган барлык төр милли конкурсларны әзерләүгә өлеш кертә. Әйтик, «Энҗеләр» һәм «Язгы чәчәкләр» конкурсларында көч сынашкан милли киемле кыз балалар рәссамны яңа әсәр язарга да илһамландырган! Киндердәге кулларына чәчәк бәйләмнәре тоткан калфаклы, милли киемле татар кызчыкларына карап туймаслык! 2021 елда Алена Әскәровага Бөтендөнья татар конгрессының Рәхмәт хаты да тапшырылган һәм әлеге Рәхмәт хатында шундый юллар теркәлгән: «Милләтебез алдындагы олы хезмәтләрегезне искә алып, татар халкының телен, мәдәниятен үстерүдә, гореф-гадәтләрен саклап калуда башкарган зур эшләрегез өчен Бөтендөнья татар конгрессы сезгә зур рәхмәтләрен белдерә һәм киләчәктә дә уңышларга ирешерсез дип ышана!» «Мине, иҗатчы буларак, әсәрләремә, милләт хакына башкарган эшчәнлегемә игътибар булу дулкынландыра. Мондый рәсми рәхмәт хатлары дөрес иҗатта булуыма ышаныч өсти! – диде әңгәмәдәшем. – Былтыр конгрессның Чиләбе өлкәсе бүлеге рәсми чарасы кысаларында өлкә осталарының күмәк күргәзмәсе ачылган иде. Анда үз милләтебезнең бик талантлы булуы тагы бер кат расланды. Мин мондый чаралардан бик рухланып кайтам, милләтебез алдында куелган максатларның һәммәсенең дә тормышка ашуын телим!»

А. Әскәрова өч тапкыр «Артшоу» премиясенә дә лаек булган иҗатчы. Аленаның әсәрләре Третьяков дәүләт галереясында, Чиләбе Көньяк Урал дәүләт тарих музеенда, Владимир өлкәсендәге Петушки туган якны өйрәнү музеенда һәм башка музейларыбызда, бихисап шәхси коллекцияләрдә дә кадерләп саклана.

«...Җиребезнең искиткеч сихри, гаҗәеп икәнен һәр бала аңлый, моңа чын-чынлап куана. Әмма яши-яши, кешеләр үзләрендәге шушы халәтне җуя бара, шуңа күрә дә мин үз әсәрләремдә дөнья ямен чын могҗиза буларак сурәтләп, башкаларны барысына шөкер итеп, Җиребезне сакларга, бала чактагыдай һәрнәрсә белән канәгать һәм барсы өчен дә рәхмәтле булган әлеге халәтләребезгә янә әйләнеп кайтырга, кулларыбызны дөньябыз матурлыгына таба сузырга өндим!» – ди ул.

Рәссамның инде тормышның ачысын-төчесен татыган, гомер буе гыйлем эстәгән дәрвишләргә багышланган тулы бер сериясе дә үзенчәлекле килеп чыккан һәм күз ачып йомганчы сатылып беткән! Бу серияне караганда Ж.Руминең бер гыйбарәсе хәтергә килә: «Син – океандагы бер тамчы түгел, ә тамчыдагы – бер океан»... «Күп кенә әсәрләремне хәтта фотосурәткә төшереп калырга да җитешмим! Билгеле, картиналарымны ошатып алучылар булу минем өчен куаныч!» – ди Алена Сәгъдулла кызы.

А. Әскәрованың иҗатында Аллаһы Тәгаләнең гаҗәеп төрле мәхлуклары, әйтик, балыклар, кошлар бик еш сурәтләнә. Аның әсәрләрендә чәчәкләр дә, бакчадан яңа гына җыеп кергән сусыл алмалар да, диңгезләр дә бар. Диңгез-океаннарыбызның үзгәреп торган кәефен, илаһилыгын, хөр стихия булуын исәпкә алган иҗатчылар һәрчак бу темадан читтә калмый. Алена ханым картиналарындагы гаҗәеп чиста, берничә дистә төсмерле диңгез дулкыннарыннан күзне аерып булмый! Ә менә 2019 елда иҗат ителгән «Энҗе йөртүче» әсәрендәге диңгез аша без Ана булу шатлыгын тоярга әзерләнгән, эчтән балкып торган хатын-кыз образын күрәбез. Ә «Игелек» картинасында – якты, кышкы дөньяга сокланып туя алмаган ир бала образы! Оптимизм бөркелеп торган әсәрләр болар! Алена Әскәрованың киләчәктә ясалачак картиналары милли тема белән берләштерелеп иҗат ителәчәген искә алсак, бу эшләрнең кабатланмас стильле, тәрбияви мәгънәле, зәвыклы эстетикада булачагын күзалларга мөмкин! Бөтен булмышыбызга шатлана белү – менә нинди хискә өнди безне милләттәшебез!

Рәссам ханымның әле күптән түгел генә иҗат иткән яңа әсәре – нәсел көче турында. «Нәсел көче – ул кодрәтле, шифалы энергия! Шушы энергия һәм үз нәселебез хатирәләре җанга терәк бирә дә. Әлеге картинамны ясаганда үз җаныма да шифа таптым, – дип аңлатты талант иясе. – Мин һәр көнне әниемә, үз гаиләмә һәм бар нәселемә рәхмәтле! Чөнки без үз якыннарыбыз һәм үз тамырларыбыз белән көчле! Һәм бүгенге бөтен барлыгым аларның һәрберсенең өлеше һәм, билгеле, Аллаһы Тәгаләнең безгә карата олуг мәрхәмәте белән бәйле!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ИБНЕ ФАЗЛАН

●Болгарларның ислам кабул итүе. Эскиз. Фәрит Вәлиуллин эше. .

(Дәвамы. Башы 18 нче санда).

Р.Фәхретдин тәрҗемәсендә кыскартулар Якут Хәмәви язмасының тулы булмавына бәйледер кебек. Р.Фәхретдин үзе фикерләренә туры килмәгән өлешен төшереп калдырырга мөмкин.

Б.Урманче язганча, Р.Фәхретдин сәяхәтнамәне 16 бабтан һәм 105 маддә-абзацка бүлгән. А.Ковалевский тәкъдим иткән Мәшһәд нөсхәсенең төп факсимиле һәм тәрҗемә текст нинди дә булса бүлекләргә бүленмәгән. Галим, нигездә, ибне Фазланның Болгарга сәяхәтенә багышлаган мәгълүм текстларны бергә туплап бирергә тырышканлыгы аңлашыла. Шул исәптән, Р. Фәхретдиннең СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы архивында сакланган текстын һәм аның факсимилендә китапка урнаштыруны тиеш санаган. Кызганыч, текстның тәрҗемәсе һәм кулъязмасы Б.Урманче күчереп кайткан кулъязмага таянып башкарылган кебек. Басманы төзүче буларак, безләр, бу күренешкә игътибар итмичә булдыра алмадык. Автор-төзүче ни өчендер Б.Урманченың исемен күрсәтүне кирәк тапмаган. 454 нче битендәге «Китапның тышлыгы үзәрендә «18 бит» дип язылуы дөрес түгел. 18 кәгазь яисә 18 сәхифә дип язарга кирәк. Димәк, 18 сәхифә – 36 бит була. Габделбакый, 1968», дигән искәрмәгә нигезләнеп кенә кулъязма текстның кемнән алынуын чамаларга мөмкин. Б.Урманченың кулъязмасы төзүче-авторга яхшы таныш булуы, факсимиленең дә рәссам күчергән кулъязма буенча эшләнгәнлеген дәлилләргә ярдәм итә.

Хәзер кыскартуларга тукталыйк. Р.Фәхретдин бүленеше буенча беренче бүлекнең тәүге абзацында соңгы җөмлә төшеп калган, ягъни Ибне Фазланның Болгарга килү сәбәбе ачылмыйча кала. Ковалевский тексты буенча эшләнгән Ә.Хәйри тәрҗемәсендә абзац болайрак тәмамлана: «Шулай итеп, аңа (хәлфәнең илчесенә) аның өчен (Болгар патшасы өчен), аның хатыны өчен, аның уллары өчен, аның ир туганнары өчен, аның (кабилә) башлыклары өчен бүләкләр һәм аларны Болгар патшасы сорап Нәзиргә язган дарулар тапшырылды» җөмләсе төшерелеп һәм икенче абзацтагы «921 елның 21 июнендә» кузгалу хәбәре генә теркәлгән. «Хорезм мәмләкәте» бүлегендә 6 нчы һәм 7 нче абзацлар кыскартылган вариантта, 11 абзац 4 нче абзацка кушылып киткән. «Газия халкы» бүлегендә 17 нче абзац кыскартылган һәм берләштерелгән. 8-10 абзацлар 17–27 абзацларга берләштерелгән. 28 нче һәм 29 нчы абзацлар бергә кушылган. 33 нче абзацта тау һәм елгалар хакында сүз бара, Р. Фәхретдиндә төшеп калганнары да бар. «Печенклар» бүлеге 34 нче абзацка берләштерелгән, шактый кыскартылган һәм кайбер фикерләр генә алынган. «Болгар кавеме» бүлеге тулысы белән алынган. «Болгарга якынлашу» 41–80 нче абзацларны эченә алып, 42 нче абзацны ни өчендер 80 абзацка күчергән. «Болгарга килеп җитү», «Алып батыр», «Рус халкы», «Хәзәрләр» бүлеге тулысы белән алынган. Кызганыч ки, бездә Якут Хәмәви тексты булмау, төп текст белән чагыштыру мөмкинчелеген бирмәде.

Әхмәд ибне Фазланның Болгарга сәяхәтенә рус галимнәре XIX гасырның беренче яртысында игътибар итә башлый. Тәүге тапкыр Россия Академиясе академигы Христиан Френ тарафыннан немец теленә тәрҗемә кылына. Ул, нигездә, искә алынганча, Якут Хәмәви текстына таянып башкарыла. Татар мәгърифәтче һәм дин галиме, тарихчы Ш.Мәрҗани дә Хәмәви буенча истә калганнарын «Мөстафадел әхбар»... китабына теркәп калдыра алган. Морад Рәмзинең 1908 елда Оренбург шәһәрендә нәшер ителгән «Тәлфик әл-әхбар»... ике томлык хезмәтендә Якут Хәмәви нөсхәсеннән өзек алган. Шулай ук XX гасыр башында Р.Фәхретдин дә Хәмәви тексты белән эшли.

XX гасырның 20 нче елларында, аерым алганда, 1923 елда татар-башкорт галиме З.Вәлидинең Иран дәүләтенең Мәшһәд шәһәрендә Әхмәд ибне Фазланның бердәнбер тулы кулъязмасын табып, матбугатта бастырганнан соң рус һәм татар галимнәре арасында тәрҗемә текстка карата шактый каршылыклы фикерләр барлыкка килә. Бу күренеш, бигрәк тә ориенталист галим һәм тарихчы А.Ковалевский тарафыннан Мәшһәд нөсхәсен рус теленә тәрҗемәсеннән соң башлана. Төп бәхәс, әлбәттә, немец һәм рус галимнәренә каршы татар галимнәренең «сакләб» төшенчәсенә төрлечә мәгънә салып тәрҗемә итү, төрлечә аңлатуга бәйле. Х.Френ һәм А.Ковалевский «сакләб»не фәкать «славян» мәгънәсендә уку яклы. Татар галимнәре, ягъни Р.Фәхретдин, З.Вәлиди, Җ.Мамедов, С.Шәмси, Ә.Хәйриләр сүзнең мәгънәләренә төрле яктан якын килеп «сакләб»нең «славян» буларак тәрҗемә ителергә тиеш түгеллегенә басым ясый. Ә.Хәйри исә Ковалевскийның төрки телләрне камил белмәвен искәртеп, гомумән, аның тарафыннан башкарылган тәрҗемәдә киткән төгәлсезлекләрне аерып, аңлатмалар биреп бара. Бу урында «сакләб» хакында сүз алып барабыз икән, һәрбер галимнең фикерләренә аерым туктау кирәктер, мөгаен. Иң элек Б.Урманченың шәхси архивында сакланган фикерләрне искә алып китү дә зарар итмәс.

Б.Урманче сәяхәтнамәне күчергәндә «сакләб» төшенчәсе буенча үз күзаллавын, ачыклауны теләп, аерым кәгазьләрдә фикерләрен теркәп барган. Рәссам, шулай ук рус галимнәренең фикерләре белән килешми, ул төрле чыганаклар, сүзлекләргә мөрәҗәгать итү кирәклеген искә ала. Бу урында шуны да искәртү кирәктер: Б.Урманче күп кенә бәхәсле мәсьәләләргә язган мәкаләләре яисә искәрмәләрендә сүзнең мантыйкый нигезе буенча фикер йөртеп эшли һәм дәлилләргә тели. «Сакләб» сүзенә тирәнрәк төшү нияте белән Европа телләре, аерым алганда итальян теле сүзлегеннән дә карау кирәк дип саный. Мәсәлән, бер кулъязмасында бу хакта түбәндә болайрак искә ала: «Сакләб – итальян сүзлегеннән карарга. [җәнуһларда] кол белән сату иткәндә таралган сүз түгелме? Сакаләб коллар мәгънәсендә. Р.Ф. сакләб диеп алуы дөрес булырга кирәк. Аның гарәпчәне белүе шөбһәсез. Аның өстенә шәрыкны, мөселман шәркын яхшы белүче. Ул бу [сүзләрне] икеләнмичә эшләтә. Башка исемнәр берлек сыйфатында булса сакләб, сакаләб күплек сыйфатында язылган». Рәссам, рус чыганакларында язылганча бирелгәндә сакаләб коллар мәгънәсендә килә дип саный. Б.Урманче славян сүзе итеп тәрҗемә итү дөрес булмавын дәлилләгән шәхси архивта икенче бер чыганакта: «Ковалевский «славян» ди. Әгәр «сакаләб» славян мәгънәсендә булса, ул сүздән алда «вә әр-рус» диюнең нинди мәгънәсе кала? Руслардан башка халык «славян» диеп аталмаган бит,» – дип яза. Әгәр дә шулай икән, текстка «вә әр-рус» сүзе кертү артык дип искәртә. Әхмәд ибне Фазланның сәяхәтнамәсен татар теленә тәрҗемәгә алынган Р.Фәхретдиндә дә «сакләб» төшенчәсенә сораулары булган һәм аның мәгънәсенә түбәндә үз аңлатмасын бирә, этимологик анализ ясый. Р.Фәхретдин фикерләренә игътибар итик: «Унсигезенче гасыр урталарында: «Ибне Фадлан болгарларны славян кавеменнән дип хәбәр бирә, шуның өчен болгарлар славян кавемнәре булыр», дигән бер фикер таралган иде. Соңгы вакытларда шушы фикернең ялгыш икәнлеге ачык мәгълүм булды. Ялгышуның сәбәбе: әлеге кешеләрнең Ибне Фадлан гыйбарәсендәге «сакъләб» сүзен «славян» дип тәрҗемә итүләредер. Бу кешеләр бу көннәрдәге Мисыр һәм Сүрия гарәп язучылары телендә «сакъләб» сүзе «саклау» сүзеннән гарәпчәләштерелгән дип фикерләгәннәр һәм «саклау» белән «сакъләб» бер нәрсә, шуңа күрә болгарларның славян булулары бар, дип хөкем йөрткәннәр. Әмма чынлыкта, Ибне Фадланның «сакъләб» дип сөйләгән кавеме славян түгел, бәлки финдыр», – дип яза, бу җирләрдә яшәгән төрки халыкларга күрше булган фин кавеме белән гомер сөрүенә ишарәли. Бик теләмичә генә булса да, А.Ковалевский да «сакләб» төшенчәсен киңрәк аңлатырга теләп «Основное значение слов «сакалиб», безусловно, «славян». В расширенном понимании им обозначали основную массу народов севера – также финнов, булгур, германцев. В этом случае применение слов «сакалиба» варьирует в зависимости от автора в той области, которую он описывает. В данном произведении Ибн Фадлан называет царя булгар «царь славян» желая представить его как могущественного властелина северных народов и тем придать большее значение отправленного к нему посольству». Ковалевский «сакләб»ләрне ничек кенә «төньяк халыклары» итеп аңлатмасын бирергә теләсә дә, нигездә, сүзнең тәрҗемәсе «славян» икәненә аерым басым ясый. Кызганыч, Х.К.Баранов төзегән «Гарәпчә-русча сүзлек»тә «сакләб» славян мәгънәсендә тәкъдим ителә. Л. Будаговның «Сравнительный словарь турецко-татарских наречий» (Санкт-Петербург, 1869) китабында «төньяк халыклары» рәвешендә, ә «Фарсыча-русча сүзлек»тә «славяннар» буларак бирелгән. Ә.Хәйри мондый хата Х.Френ тәрҗемәсендәге текстган килә, дип саный. Тарихи яктан килгәндә, «сакләб» төшенчәсенә «славян» мәгънәсен бирү XIX гасырның 30 нчы елларыннан башлап килүе аңлашыла. Бу – рус чыганакларында. Безгә мәгълүм булган татар чыганаклары «сакләб»не төрки телгә якын вариантлар белән эш йөртә. Югарыда искә алынганча, Р.Фәхретдин бу сүздә «фин» кавемен күздә тотса, инде З.Вәлиди тапкан Мәшһәд нөсхәсенең тәрҗемәсендә «сакләбләр дип гарәпләр аксыл тәнле төрекләрне, Иделнең урта һәм түбән агымында утырган фин халыкларын һәм германецларны йөрткәннәр», – дип аңлата. Монда азмы-күпме Р.Фәхретдин фикере белән охшашлык та бар. Ә.Хәйри исә, «сакләб»нең славян түгеллеген дәлилләргә теләп, үз юрамасын бирә һәм сүзгә лингвистик анализ ясый. Ул фикерен түбәндәгечә аңлата: «Гарәп теле грамматикасында хәзерге заман фигыльдән соң хәзерге-киләчәк заман фигыле шәкеле бар. Ул исә хәзерге заман фигыленә «сәүфә» яки «сә» алкушымчасы (префикслары) кушылып «сиклиб» яки «йәклиб сәүфә» рәвешендә ясала һәм төрки телдә болгар «әйләндерү» «болгар» мәгънәсен белдерә. Хәзерге-киләчәк заман фигыленең соңгы шәкелендәге «болгар» сүзе соңыннан төрки телдә «болганып яшәүче», «аралашып яшәүче» (кабиләләр кушылмасы) мәгънәсендә белдерүче «болгар» («булгар») дип тулы бер халыкның этнонимы буларак гамәлгә кереп киткән. Әмма бу кулъязма китапны күчерүче, үзенең игътибарсызлыгы аркасында, бик күп хаталар



сәяхәтнамәсе

җибәргән һәм сүзләрнең дөрес язылышын да, менә бу очраклардагы кебек, күп кенә сүзләрнең мәгънәләрен үзгәрткән. Сиклаб (гарәп әлифбасы «син» хәрефе белән язылган – **З.М.**) кульъязма китапның төп нөсхәсеннән күчергәндә, хәзерге заман фигыленең «йа» алкушымчасын (префиксын) төшереп калдырып, аны сәкълаб (гарәпнең «син» хәрефе белән язылган – **З.М.**) шәкелендә калдырган, ләкин монда күчерүче тагын бер хата ясаган һәм хәзерге-киләчәк заман фигыленең алкушымчасы (префиксы) кыскартылган шәкеле «са» урынына эмфатик (каты әйтелешле «с» (гарәп телендә «сад» формасында әйтелә) хәрефен язып куйган. Нәтиҗәдә, кабиләләр кушылмасы этнонимын белдерүче «болгар» («булгар») сүзенең беренчел язылышы танымаслык булып үзгәрә һәм бу сүзне барысы да «сәкълаб» (сәкалабәт) урынына саклаб (саклабәт) шәкелендә яза башлыйлар, ә бу, үз чиратында, тарихи чынбарлыкны күпсанлы бозып күрсәтүләргә, ялганлауларга һәм дөрес булмаган аңлатмаларга китерә», – дип үз фикерен җиткерә һәм бер үк вакытта бу фикер үз чиратында шактый каршылыклы уйларга урын калдыра. Ә. Хәйри Әхмәд ибне Фазланның Болгарга сәяхәтен Мәшһәд нөсхәсе буенча эшләгән А.Ковалевский тәрҗемәсенә нигезләнеп башкарылу инде югарыда әйтелде. Кульъязманың факсимиленә игътибар итсәк, сүз «сакләб» рәвешендә бирелә. Дөрес, Х.Баранов сүзлегендә, Ә.Хәйри язганча, «сакләб» (славян) һәм «сәкълаб» «болгау» мәгънәсен биргән нечкә «с» шәкеле белән язылган сүздә бар. Ләкин тәрҗемәгә болай якын килү, беренчедән, шикләндерсә, икенчедән, фәннилектән качу булыр иде. Тарихи яктан килгәндә, урта Идел буенда славяннар яшәмәгәнлеге билгеле, әлбәттә. Бу очракта, Р.Фәхретдиннең «финнәре», З.Вәлидинең «аксыл тәнне төрекләр» варианты күпкә фәннилеккә якын тора, дип әйтергә мөмкин. Чынлыкта, урта Идел фин һәм төрки кавемнең тарихи ватаны исәпләнә.

А.Ковалевский Ибне Фазлан сәяхәтнамәсенә багышлап язган мәкаләләрендә, Зәки Вәлидинең «сакләб» төшенчәсенә биргән аңлатмасына каршы килеп, сүзнең бары «славян» буларак тәрҗемә ителергә тиеш, дип саный һәм З.Вәлидинең карашларын тәнкыйть утына тотып, аның фикерен кире кагарга тели. Кызганыч, А.Ковалевский фәннең төп прицыпларыннан берсе – тарихилыкны онытып җибәрә кебек. Хәер, монда гарәп теле белгече, тарих фәннәре докторының коммунистлар фиркасенең идеологик принципларын алга сөрүен күрмичә үтеп булмый, әлбәттә. Ул заманда башкача аңлату мөмкин дә түгел. Тарих – идеология коралы, аңардан качып котылып булмый.

Ибн Фазланның Болгарга килү тарихының рус галимнәрен кызыксындырган икенче сәбәбе: сәяхәтнамәдә рус халкы, аларның мәҗүси гореф-гадәтләре, йолалары хакында шактый бай мәгълүмат бар дип уйлауларыннан да килә. Бу фикер дә беренчел чыганакны өйрәнергә ихтыяҗ тудыргандыр. Ләкин монда аеруча бер әһәмиятле якка игътибар итмичә булмый. «Сакләб» сүзенә гарәп теленнән тәрҗемәдә «славян» буларак тәкъдим итеп, сәяхәтнамәне үз ихтыяҗларына буйсындырырга теләүләре булса, икенчедән, язмада рус халкының гореф-гадәтләрен тасвирлануын истә тотып, рус дәүләтенең тарихын, аларның географик яктан таралышын киңәйтү омтылышын сиземләргә мөмкин. Һәм шуңа өстәп, материалны идеологик максатлардан файдалану уе өскә чыгуы да ачык күренә. Текстны матбугат өчен эшләгән Б.Урманче дә бу мәсьәләдә шиген белдерә. Югарыда искә алынганча, ул: «Әгәр «сакаләб» славян мәгънәсендә булса, ул сүздән алда «вә әр-рус» диюнең нинди мәгънәсе кала? Руслардан башка халык «славян» дип аталмаган бит», – дип, теркәп калдырган. Икенчедән, «Ибне Фазланның Болгарга сәяхәте» текстында да игътибарга алырлык абзац-маддә бар. Мәсәлән, хәзәрләр бүлегенең 88 нче абзац-маддәсендә: «Күбрәк ризыклары дөге берлә балык булып, башка нәрсәләр Рус вә Болгар һәм Киев шәһәрләреннән киләдер», – дигән җөмләдән күренгәнчә,«рус» һәм «Киев» атамаларының аерым язылуы ук бу исемнәрнең мәгънәләре бөтенләй башкача яңгыравына ишарәли. Сәяхәтнамәдә игътибарны җәлеп итәрлек тагын бер мисал: Болгар дәүләтенең, нигездә төньяк халыклары белән сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләре, дөресрәге, текстан аңлашылганча, «вәйсү»ләр (весь, вепслар) белән аралашулары «рус» төшенчәсенә башкача карарга һәм аңлатырга этәргеч бирә. Чыннан да, текстагы «рус» сүзе бүгенге рус халкына туры киләме, әллә Рус дәүләтенең дәүләт буларак оешуында зур роль уйнаган «русь»лар, ягъни нармон-варяглар күздә тотыламы? Рус галимнәре иң беренче чиратта Киев русена басым ясарга тели, әлбәттә. XX гасыр башы рус чыганагына игътибар итик: «Ёще в 1823 году Френ указал на истинную причину того, что арабские писатели до Рюриха совершенно не упоминают о Русах. […] Иногда делали попытки искусственным образом ослабить его значение; однако открытие каждого нового свидетельства о Славянах и Русах 9-го столетия постоянно вновь подтверждало то положение, что более древние восточные писатели до Рюриха знают лишь Славян, о Русах же напротив, упоминают лишь со времени Рюриха и его непосредственных преемников», – дигән фикер белән очрашабыз. Язманың авторы – А.Куник (Арист Аристович Куник (1814-1899), россияле тарихчы). А.Куник «рус» төшенчәсенең нигезендә нармон-варяг мәгънәсе ятуын ачыктан-ачык белдерә. Шунысы гаҗәп: рус тарихчылары Ибне Фазлан текстындагы «рус»ны никадәр генә бүгенге рус халкына бәйләргә тырышмасын, чынлыкта, А.Куник билгеләп узганча, гарәп сәяхәтчеләр өчен, төньякта яшәгән халыкларны славян дип атап йөртү булган. Гомумән, автор искәрткәнчә, X гасырга кадәр руслар дигәндә, славяннарны берничек тә күз алдында тотылмавын күрәбез. Һәм төп нәтиҗәне болайрак ясарга туры килә: Ибне Фазлан үзенең сәяхәтнамәсендә чынлыкта нармон-варяглар, аларның мәҗүси йолалары, гореф-гадәтләрен сурәтләгән, ә «славян» төшенчәсе исә, гарәп сәяхәтчеләре өчен «төньяк халыклары»ның мәҗүси яшәү рәвешләрен чагылдырган хезмәт булган дигән нәтиҗә чыгарырга мөмкинлек тудыра.

Чынлыкта, татар халкының тарихы рус чыганаклары нигезендә генә тикшерелә. Югыйсә, төрки халыкларның географик яктан таралышы, яшәеше Урта Азия, Себер киңлекләрен эченә алган. Төркиләр кытай һәм фарсы, гарәпләр белән аралашкан, сәүдә итешкән, мәдәни бәйләнешләры да шәрык белән бәйле. Төп чыганакларны шулардан эзләргә кирәктер, мөгаен.

X гасырга караган Борынгы Болгар дәүләте, аның халкы турында язылган тарихны без Ибне Фазлан хезмәте аша таныштык. Гарәп сәяхәтчеләре бу җирләрдә XI-XIII йөзләрдә дә булып киткән. Аларның язмаларында да болгар тарихын ачарлык шактый кызыклы мәгълүмат табарга мөмкин. Форсаттан файдаланып, Болгар дәверен тасвирлаган Ибне Баттутаның «Төхфәтен-наззар фи гараибел-әмсар вә гаҗаибел-әсфар» китабыннан Дәште Кыпчакка караган өлешен Р.Фәхретдин татарчалаштырган «Ибне Баттутаның Дәште Кыпчакка сәяхәте»ндәге (Оренбург, 1917) «Болгар шәһәренә сәфәр» бүлеген дә, икенче бер гарәп географы, сәяхәтчесе Шәмсетдин Демәшкыйның «Нәхабәт әд-дәһр фи гаҗаиб әл-барра вә әл-бәхр» китабындагы Болгар, Бортаслар, Хәзәрләр хакында язмасын да, Әл-Мәсгудинең «Мөрүҗ-з-зәһәб» исемле китабының 2 нче томы 12 сәхифәсен һәм Ибнел-Әсирнең «Әл-Камил фи әт-тарих» («Гомуми тарихның тулы җыентыгы») исемле китабының 9 нчы томының 173-174 нче битләрендә Болгар дәверенә караган кыска өзекләрнең барлыгын да искә алып китү кирәктер. Боларга өстәп, Әл-Гарнати китабында да XIV гасырдагы Болгар дәүләте, тарихына да шактый материал таба алабыз.

XX гасырның икенче яртысында татар гуманитар фәнендә халкыбызның борынгы Болгар тарихын өйрәнүгә игътибар артса, сынлы сәнгатьтә дә Ибне Фазланның Болгарга килүе, ислам динен рәсми кабул итү, болгар тарихын тасвирлаган рәсемнәр шактый ясалды. Гуманитар фәндә Болгар дәверенә караган күп кенә бәхәсле мәсьәләләргә җавап эзләү, тарихи дөреслеккә омтылу күзәтелсә, сынлы сәнгатьтә исә, борынгы бабаларыбызның үткән тарихын, гореф-гадәтләрен, йолаларын, Ибне Фазлан сәяхәтнамәсендә сурәтләнгән вакыйгаларга нигезләнеп, бүгенге укучының аңында үткәннәргә ихтирам, тасвири сурәтләр аркылы, тарихи аң тәрбияләүне төп максат итә. Ничек кенә булмасын, фәнни караш һәм сәнгати тасвирның милли үзаң уятуда тәэсир көче биниһая зур, әлбәттә. Татарстан рәссамнары Б.Урманче, К.Нәфигов, Р.Заһидуллин, Ф.Халиков, Ф.Вәлиуллин, Ф.Гыйльфанов, Р.Шәмсутов, К.Руденко һ.б.ларның тарихи вакыйгаларны рәссамнар күзлегеннән бүгенге дөньяга таныту, тарихи хәтерне төсләр белән ирештерү, үткәннәргә ихтирамны тагын да арттыра, әйтерсең лә шул заманның бөтен картинасы безнең күз алдына килеп баса сыман. Аларда шул дәвернең психологик халәте, кешеләре, яшәешләре, гореф-гадәтләре, йолалары, тормыш көнкүрешләре, тарихи хәтере ачык чагыла, хәтердә яңара.

Ибне Фазланның Болгарга сәяхәте күп телләргә тәрҗемә ителгән, бүген дә ул процесс дәвам итә. Рус гуманитар фәнендә Ибне Фазланның Болгарга килү хакындагы сәяхәтнамәсенә кабат кайтып, яңача аңлатырга теләү, идеологиягә буйсындырырга теләү сизелсә, татар галимнәре исә тарихи дөреслекне күрсәтүне алгы планга куя.

Р.Фәхретдин XX гасыр башы милли күтәрелеш рухында тәрҗемәгә алынган. XX гасырның ахыры – XXI гасырның башында исә, татар гуманитар фәне бүгенге көндә халык хәтерендә сүнә барган тарихи хәтерне кабат уятуны максат итеп, борынгы Болгар тарихына караган чыганакларны ничек кенә һәм ни рәвешле генә булмасын укучыга җиткерү юнәлешендә эшли. Без тәкъдим итәчәк хезмәт тә шундыйларның берсе. Ибне Фазланның сәяхәтнамәсен өйрәнү болар белән генә чикләнмәс, алар һәрдаим басылыр, яңача күзаллау, яңача аңлатулар да булыр. Ләкин шунысы бәхәссез: Ибне Фазланның Болгарга сәяхәте бүгенге Идел буе халыклары, шул исәптән рус дәүләтенең нигезен коруда, аларны берләштерүдә әһәмиятле роль уйнаган рус, ягъни нармон-варягларның борынгы тарихын ачуда төп чыганакларның берсе булып кала бирә.

Зөфәр МӨХӘММӘТШИН.

Гобойчы, Татарстанның атказанган артисты Мөбарәк Вазыйх улы Баттал 1912 елның 15 маенда элекке Спас өязе (хәзер Алексеевск районы) Зур Тигәнәле авылында крестьян гаиләсендә туа. Исән калган бертуганнарыннан ул дүртенче бала була.

Батталларның

...Мөбарәк абыйга – энекәш, миңа эти тиеш Фуат Батталов балачактан Мөбарәк абыйның шундый хатирәләре калган, дип сөйләде: «...Йорттагы һәм кырдагы эшләрне өлкәннәр – әтиебез, әниебез, Ләйлә апа һәм Галимҗан абый башкара. Калганнарыбыз әле зур эшкә ярамый; вак-төяктә катнашып, кул арасына кушылабыз. Минә шул «калганнар» рәтенә Салих абый белән мин дә керәм. Безгә бала карау, вак-төяк йомышка йөгерү кебек эш кушыла. Шуннан арткан вакыт уенга китә. Тагын Сәетбаттал бабайның да еш искә алам. Бабай инде картайган, аяклары да авырта, мәчеткә бара алмый, өй эчендә генә ыңгырашып атлап йөри; күбесенчә урын өстендә, мендәренә таянып яткан хәлдә вакыт уздыра. Шундый бер чакта ул мөлаем тавыш белән безне – оныкларын чакыра: «Уларым, килегез әле, бабагызның ничегрәк йөргәнен күрсәтегез әле», ди. Галимҗан абый, Салих абый бабай янына йөгерешеп килә, мине дә чакыралар. Салих абый: «Әйдә, син дә йөреп күрсәт; эләксә, өчебезгә бергә эләгер», дип үз янына әйди. Әйтерсең ул бу «спектакль»нең режиссёры иде. Өчәүләп тезелешеп баскач, иң элек бабай булып Салих абый йөреп күрсәтте. Бер кулын тезенә куеп, чак кына бөкрәеп, алга атлады да, «Әй!», дип куйды, икенче адымда – «Алла!» Без Салих абыйны кабатлап бардык. Бабай рәхәтләнеп, күңеле булып көлде...».

Бер кыш көнне Мөбарәк тимераякта йөргән. Су буена барган тар сукмакка кызлар ташыган су тамып, аяк асты бозланган. Ашыйсы килеп, Мөбарәк шуннан бер шуып төшә дә, өйләренең моржасына карый: төтен чыгамы, әни аш пешерә башламаганмы әле? Шул вакытта бер кыз суга килеп, аңа чиләгәнә куйган язу тапшыра: чиләк төбен карале, монда синә хат, кеше күрмәслек укы, ди. Бөтен җирдәге кебек, авылда да хәбәр тиз тарала, шуңа күрә кем кем белән йөргәнен хатын-кызлар аша халык тиз белеп китә. Хатта кыз бу көннәрдә өй аулак кала, ди, шуңа күрә төнгә таба – кеше күрмәсен өчен, хәтта рекрут малайлар да узып киткәч, Мөбарәкне гармун белән килеп кич уздырырга чакыра. Күрше Мостафа белән килермен, дигән Мөбарәк аңа.

Егерменче еллардагы ачлыктан котылу өчен, Мәскәү өлкәсенә Ләйлибәдәр апасы, җизние Гариф белән китеп торган бертуганы Салих ике елдан авылга кайткач, аннан Галимҗан абыйлары туенда биергә үтенгәннәр. Ул: «Юк, җир өстендә биеп булмас, үкчәләр бәргәндә тавыш ишетелсен», – дигәч, тупсадан капканы салып куйганнар. Менә хәзер биеп була, дип Салих авылдашларын баштта «чечетка», аннары Мәскәүдә күреп өйрәнгән, русларча «утырып бию» белән («вприсядку») шаккатырган. Ә Мөбарәк Салихка рус биюендә кушылып, гармунда «Барыня» көен уйнаган.

1930 еллар башында авыл җирләрен радиофикацияләү башлана. Мөбарәк абый хатирәләреннән: «Безнең ике катлы волисполком бинасы бар иде, шунда бөтен авыл халкы җыелып, концерт тыңлыйбыз. Музыкага якынаюым этидән килгәндер. Безнең үзебезнең өйдә дә патефоныбыз бар иде. Безнең эти музыка һәвәскәре булган, гармунда, курайда уйный белгән, скрипкада уйный иде, иң беренче граммофон сатып алучы да ул булган. Шулай итеп, музыка авазлары бишектән үк безгә ишетелеп торган. Олы картлар сөйли торган иде: безнең эти урманнан курай исемле үсемлекне кисеп, курай ясап уйный иде. Мин бәләкәй чакта авылда гармунда уйнарга өйрәндем. Кулыма ни эләксә, шуннан көй чыгара идем, хәтта кабак көпшәсеннән пәке белән ясаган курайда уйнаганым бар; юкә кабыгыннан көй чыгарган чаклары бар иде. Зур максатым – белем кирәк иде, укуга дәртем көчле иде. Менә колхоз төзелеше башлангач, шәһәрдән төрле вәкилләр килә башлады. Беркөнне җыелыш ясадылар, бераү чыгыш ясады, аны оратор дип уйладык. Карасак – бу журналист, драматург, җырчы Камил Мотыгый – Мотыйгулла Төхфәтуллинның малае булып чыкты. Соңыннан мин аңа укырга исәбем барлыгын җиткердем. Кадрлар кирәк безгә; нәрсәдә уйный аласың, ди. Җавап бирдем инде; ул: әлбәттә, кил, ди; адресын бирде».

1934 елда Мөбарәк Казанга килеп, музыка техникумына керү өчен имтихан тота: «Имтиханнарны Литвинов дигән бер олы кеше, атаклы дирижёр алды. Ишетү сәләтең бар, физик яктан сәламәтсең, сине укырга алабыз, гобойда уйнарсың, диде. Син аның нәрсә икәнен дә белмисеңдер, минем оркестрга гобойчы кирәк. Оркестрда аның урыны бик дәрәҗәле; бөтен Татарстанда андый инструмент юк әле, бу синең гомерлек ипиең булыр, ди. ...Тулай торакта карыйм – бер зур бүлмә, берәү виолончельдә уйнап утыра (мин виолончельне да белми идем әле), ул Фәрит Яруллин булып чыкты».

1938 елда Казан музыка училищесын тәмамлап, Мөбарәк Баттал «Башкаручы һәм укытучы» һөнәрен ала. Шул ук елда ул Мәскәүдә рабфак, аннары консерваториянең икенче курсына гобой буенча укырга керә.

«Казанда училище тәмамлаганнан соң, Фәрит белән Мәскәүгә күчтек. Шушта музрабфакка, аны бетергәч – консерваториягә кердек. Мин барганда Җиһанов, Заһид Хәбибуллин, Фәрит тулай торакта яши иде инде. Мине – икенче, Фәритне беренче курска алдылар. Казанда Фәрит бер курска алда иде, монда – бер курска түбән. Аннан соң ул үзенең кәсебен дә, специальностен дә үзгәртте – виолончельдә уйный иде, хәзер композиторлык бүлегенә имтихан тотты».

Училищеда укыганда ук, Мөбарәк күчмә бригада составында Мәскәүдә «Баррикада» кинотеатры оркестрында да эшли, аннары Кызыл Армия театрына күчә. Кинотеатрларның үз оркестры отпускка киткәндә, киносеанс алдыннан уйнап, студентлар акча эшләп ала.

Мәскәүдә Мөбарәк профессор Солодуевтан дәресләр ала, композитор Александр Гедике җитәкчелек иткән камера оркестрында уйный. Яхшы укыганы өчен, аңа консерватория ректоры Шацкий исемендәге персональ стипендия бирелә. Бу стипендиягә аеруча сәләтле студентлардан бары тик өч кеше генә лаек була. Мөбарәкнең танышы, шагыйрь Муса Җәлил, яхшы укыганың өчен сиңа стипендия биргәннәр, дип аны кулын кысып котлый.

Мөбарәк Батталның Мәскәүдә укыган елларда бертуган абыйсы Салих шунда ук хәрби хезмәт уза. Консерваториягә укырга кергәндә, Мөбарәк Салих хезмәт иткән хәрби аэродромга барган; Салихның сынау отрядыннан мәшһүр очучы полковник Александр Анисимов аны самолётта очыртырга тәкъдим иткән. Әмма Мөбарәк экзаменга ашыгып, очудан баш тартырга мәҗбүр булган. Салихның бүтән хезмәттәше, соңыннан аның турында «В небе Чукотки» исемле китабында язган очучы Михаил Каминский да ачык кеше булган, Мөбарәк белән «син» дип сөйләшкән.

Ниһаять, консерваториядә өч ел укып, Кызыл Армия театрында эшләгән чакта, Мөбарәк 1941 елда булачак татар сәнгате декадасында катнашу өчен Казанга, опера театры оркестрына чакыртыла. «Без – декадага әзерлек эшләрен алып бару өчен, Казанга кайтырга чыктык. Мәскәүдән дә, Ленинградтан да килделәр ул чакта. Бөтен вагон – безнең татар студиясендә укучылар. Бер урынга туры килгәнбез: минем янымда гына Гадел Кутуй утыра. Муса Җәлил дә шунда, артистлар арасында; җырчылар - бер группа. Гадел Кутуй белән төн буе серләшеп кайттык» (Элегрәк бервакыт Г.Кутуй Мөбарәктән: «Синең бертуганың Абдулла белән таныштым» дип, бурычка акча сораган. Аннары Камал театрына бер барганда актёр Хәким Сәлимҗанов Кутуйның бурычын Мөбарәккә кайтарган). «Декада программасына кергән зур күләмле әсәрләрдән композитор Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсы премьерасын куеп, инде «Шүрәле» балеты репетицияләренә тотынабыз дигәндә генә, Бөек Ватан сугышы башланды».

Халыкны танкларга каршы окоп казырга җибәрәләр. Шуның өчен Мөбарәкне дә Буа районына, Чәчкаб авылы янына юллыйлар. Шунда эшләгәндә, ул татарча сөйләшкән төркемне күреп ала, анда Җәүдәт Фәйзи, Гадел Кутуй һәм башка танышлары булып чыга.

●М.Баттал 1965 елның 8 маенда.

Фәрит Яруллинны озаклямый Ульяновскидагы танк училищесына җибәрәләр (Яруллин сугышка китеп, 1943 елда Белоруссиядә һәлак була һәм үзенең «Шүрәле» операсы премьерасын да күрмичә кала). «Сугышка Муса Җәлил, Фәрит Яруллиннарны озатканнан соң, чират миңа җитте. Гәскәри һөнәрем юк иде, рядовой булып киттем. Безне Мәскәүдә формалаштырдылар. Бер лейтенант килде дә, команда бирә: «Кем музыка белән бәйле – тезелешегез!». Безне элемтә взводын төзү өчен чакырганнар икән. Шул һөнәрне үзләштерергә тотындык».

Мөбарәк командарм маршал Иван Конев җитәкчелегендә Беренче Украина (элекке «Воронеж») фронтында старшина, аерым элемтә ротасы радист булып хезмәт итә башлый. 329-нчы укчы дивизия составында ул Украинаны, Польшаны азат итә; Берлинга җитә, шуннан Прагада восстание күтәргәннәргә ярдәмгә җибәрелә. Сугыш хатирәләреннән:

«Минем өчен сугыш Туладан башланды. Туланы азат иткәннән соң, көнбатышка киттек. Элемтә һөнәренә сугыш баруында өйрәнергә туры килде. Вакытлар узу белән, мин 43 нче элемтә ротасында беренче классլы радист-телеграфчы булдым. «Полуторка» әрҗәсенә көйләнгән РСБ радиостанциядә хезмәт иттем. Без укчы дивизия штабы белән алгы сызыктагы гаскәрләр белән элемтәдә тордык. Туладан соң Курск, Орёл, Украина, Польша җирләре аркылы Берлинга җитеп, сугыш беткәнчегә кадәр шушы машинада җиңү көнен каршы алдык. Берлин өчен сугышлар барганда, Чехословакия хөкүмәте ярдәм сорап безгә мөрәҗәгать итте, чөнки Прага шәһәрендә чех



Все графы заполнять полностью

Наградной лист.

1. Фамилия, имя и отчество Батталов Мубарек Вазихович
2. Звание Старшина 3. Должность, часть Старший радист 340 отдельной роты связи 329 СД
Представляется к награждению Медалью „За боевые заслуги"
4. Год рождения 1912 5. Национальность татарин 6. Партийность кандидат ВКП(б)
...
10. Каким РВК призван Казанским горвоенкоматом
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) не имеет.
...

1. Краткое конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг.
...Медалью „За боевые заслуги"

●Хәрби бүләкләү кәгазе.

гобойчы туганы

● 2002 елның 15 маенда Зур Тигәнәле мәктәбендә, клуб мөдире Мәсгут Мостафин белән.

халкы немец гаскәрләренә каршы баш күтәргән. Анда барып, Праганы фашистлардан азат иттек. Мин Җиңү көнен Прагада каршы алдым».

Минем әтием Фуатның 60 яше тулу уңаеннан 1980 елда җыелган мәҗлестә Мөбарәк абыйның әйткән сүзе истә: «Без газаплар чигеп кайтып, матур мәҗлестә утырабыз. Бик зур шатлык. Без Берлинны алганда, андый ризыклар юк иде әле. Әй, булса иде шундый ризыклар, шунда булса иде Фуат, Нурфигаль (минем әни – **Ф.Б.**), ярты тормышымны бирер идем».

Мөбарәк Берлинга җитеп, Рейхстаг стенасында акбур белән кул куйган. Германия капитуляциясе турында алар беренче булып ишетә. Үз машиналарындагы аппаратура арасында Мөбарәк гармун белән скрипка йөрткән. Бүтән частьтагы бер татар егетенә гармунны тоттырып, Мөбарәк скрипка алып, Берлин урамында шатлыктан «Эх, алмагачлары»н рәхәтләнеп уйнап җибәргәннәр!..

1945 елның көзендә ул Казанга кайта. Соңыннан Мәскәүдән аңа сугыш бүләкләрен – «За боевые заслуги», «За победу над Германией» медальләрен, өченче дәрәҗә Дан орденын җибәрәләр (1985 елда Мөбарәк 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә). Сугыштан соң яңадан яраткан уен коралын – гобойны кулына алып, опера театрына эшкә кайта.

Мөбарәк шул елда ук Рәисә Билалова белән таныша: «Октябрь бәйрәме узганда трамвайга утырып Академия театрына киттем. Алда берничә кыз бала көлешеп бара. «Сез кайчан төшәсез?» – дип сорау биргән идем, берсе әйләнеп карады: «Ленин бакчасында»... Аннан тезеп китте: «Абый, мин сезне таныйм бит, сез декадага әзерләнгән вакытта мин театрга йөри идем». Кем икәнен сораштырмыйча ничек түзим инде? «Мин Рәисә Билалова. Быел консерватория ачылды, беренче елым, шунда вокал буенча укыйм», – диди бөтен тарихын сөйләп бирде. Укып бетергәч, аны опера театрына билгеләделәр, менә шуннан башланды бергә эшләү. Миңа өйләнергә күптән вакыт: шул хакта сүз катмакчы булам. Соңыннан туктале, минәйтәм, апаларга барыйк, сине күрсәтик, җизни нәрсә әйтер, дим... Салих абый Сәйдәшев сорый: Мөбарәк, Рәисәгә өйләндеңме әле? Ниһаять, 1947 елда без кавыштык».

«Без Сибгат Хәким белән аралаша идек; безгә Хәсән Туфан килеп йөри иде. Себердән ул кайтуга ук чакырып алдык аны, пилмән белән кунак иттек, Фатих Кәримнең җәмәгатен дә (Кадрия Ишуковны)... Күңелле бит».

Мөбарәк абый, Рәисә апа өйләренә немец әсирлегеннән кайта алган подпольщиклар – Рушат Хисаметдинов һәм Гарәф Фәхретдинов та килгән. Алар Рәисә апага Рафаэль Мостафинның 1966 елгы «Воспоминания о Мусе Джалиле» исемле китабын шундый язу белән бүләк итә: «Мы, соратники М.Джалиля, Рушад Хисамутдинов и Гараф Фахрутдинов, от всей души желаем Вам долгих лет жизни и успехов в работе». Мөбарәк абыйга «Синең бертуган Абдулла белән мин дә бер төрмәдә чередем», – дигән Рушат. Менә шулай Мөбарәк абый, Салих абый һәм минем әти фашист әсирлегендә җәзалап үтерелгән унбер подпольщик, шулар арасында бертуганнары Абдулла Баттал һәм Муса Җәлил турында да ишетеп белгән...

Сугыштан соң Мөбарәк, Салих Баттал, минем әти композитор Салих Сәйдәш белән Черек Күл янындагы (Лобачевский урамында) сыраханәгә йөргән. 1981 елның җәендә мин әти-әни белән Мөбарәк абыйларга килеп, анда безнең алдан килгән Рафаэль Ильясов белән таныштык – ул радиода музыкаль тапшырулар редакторы булып эшләгән; Казан музыка училищесын Мөбарәк абыйда гобой буенча укып тәмамлаган, ләкин соңыннан җырчы булып киткән музыкант. Танылган музыкантлардан Мөбарәк абыйның дустын – композитор, виртуоз баянчы Марс Макаровны да телгә алырга кирәк. Алар тыгыз аралашкан; Макаровлар белән без Мөбарәк абыйларда кунакта очраша идек.

Мөбарәк абыйның калган бөтен иҗади тормышы опера театрында уза: ул - татар опера һәм балет театры оркестры артисты һәм солисты, 1957 елдан – ТАССРның атказанган артисты; татар музыка сәнгатенең күренекле эшлеклеләре белән бергә чыгыш ясый, С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Ф.Яруллин, А.Ключарёв әсәрләрен һәм халык көйләрен гобой өчен эшкәртеп башкара; 1950-1971 елларда Казан музыкаль училищесында да укыта. Ул тәрбияләп үстергән гобойчылар күп шәһәрләрдә симфоник оркестрларда, музыка сәнгать өлкәсендә җитәкче эшләрдә эшли. Опера театрында эшләү дәверендә Мөбарәк Баттал алтмышка якын классик опера һәм татар совет композиторларының опера-балетларын башкаруда катнаша.

2013 елда мин очраклы рәвештә Ләйлә апа Кәрим – язучы-фронтовик Фатих Кәрим кызы белән таныштым. Ул минем әти ягыннан бөтен туганнарыбызны белгәч, аның әнисе Кадрия Ишукова белән безнең Салих абыйның мөнәсәбәтләре турында ачыклау өчен Ләйлә апаны үзебезгә чакырдым. Шул ук елның 20 февралендә килеп, ул да хатирәләре белән уртаклашты: «Я когда маленькая была, мы к ним приходили – напротив КАИ они с Раисой получили комнату; и на меня гобой этот производил волшебное впечатление. Я его всё время заставляла, приставала к нему: Мөбарәк абый, сыграйте, сыграйте! И я с ним в оперный театр ходила, я даже в оркестровой яме сидела, вот, то есть он меня в оперный театр водил. Хорошие были отношения...»

1990 елның 5 маенда СССР президенты М.Горбачёв фашист әсирлегендә Гайнан Кормаш оештырган яшерен төркем әгъзаларын һәлак булуларыннан соң I дәрәҗәле Бөек Ватан сугышы ордены белән бүләкләргә дигән Указ чыгарды. Бу орденнарны тапшыру өчен 1991 елның 24 декабрендә Казан Кремленә подпольщикларның туганнары чакырылгач, шунда Мөбарәк абый барып, бертуган энесе Абдулланың ордены белән таныклыгын Татарстан президенты М.Шәймиев кулыннан алды.

2001 елның 16 маенда Абдулла көрәштәше Фәрит Солтанбәков Мөбарәк абый белән мине үзенең 85 яшьлек юбилей кичәсенә чакырды. Кичә 19 майда Карбышев урамындагы кафеда күңелле узды. Шулай итеп, Хисаметдинов белән Фәхретдиновтан соң кырык еллап вакыт үткәч, Мөбарәк абый энесе Абдулланың тагын бер көрәштәше – Фәрит абый белән таныште.

2002 елның 15 маенда Мөбарәк абый берничә туган-танышлары белән туган районына кайткан иде. Зур Тигәнәледә, район үзәге Алексеевскиның бер мәктәбендә аның 90 яшьлек юбилее уңаеннан матур кичә узды.

Алтмышынчы еллар башында җитез йөгерә алган Мөбарәк абыйдан «Трамвайда барам – урын бирмиләр. Димәк, мин карт түгел әле» дигән, ярым шаярып әйтелгән моңлы сүзләр ишеткән идек. Мөбарәк абый 2006 елның 8 декабрендә, кызы Әминәнең туган көнендә вафат булды. Ул «Сухая река» зиратында, сугыш ветераннары аллеясында җирләнде.

Фәрит БАТТАЛОВ,
Мөбарәк Батталның бертуган энесе Фуатның улы.

Айга карама кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

21 май (шимбә). ***Шәүвәл аеның 20 нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 1.09 сәгатьтә калка, 8.09 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 16.38 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Яфрагы да сихәтле

Кура җиләге яфрагы чәе бәби тапканда хатын-кызның хәлен җиңеләйтә, тик аны белеп эчәргә кирәк. Термоска 1 аш кашыгы кура җиләге яфрагы салып, өстенә 1 стакан кайнар су агызалар да, 30 минут төнәтеп, сөзәләр, суыталар. Мондый чәй аналыкны бәби табуга әзерли, аны йөклелек срогы 35 атна булганчы эчәргә ярамый. Чәйне менә бу схема буенча эчәләр: 35 атнада – көненә 1 стакан салкын чәй; 36 атнада – 1 стакан җылымса чәй; 37 атнада – көненә 2 стакан җылы чәй; 38 атнада – көненә 3 стакан җылы чәй; 39 атнада – 4 стакан кайнар чәй; 40 атнада –көненә 4 стакан бик кайнар чәй. Германиядә йөкле хатыннарга көненә 1 чынаяк кура җиләге яфрагы чәе эчәргә киңәш итәләр. Англиядә дә шулай: йөклелекнең соңгы 2 аенда, аналык тукымаларының сыгылмалылыгын арттыру өчен, бу чәйне эчәләр. Мондый чәй әле анемиядән дә саклый (Табиб киңәшеннән башка кулланырга ярамый!).

22 май (якшәмбе). ***Шәүвәл аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 1.31 сәгатьтә калка, 9.42 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.41 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Тайтояк айныта

Эчкечелеккә сабышкан кешеләрне аракыдан биздерү өчен тайтояк (копытень) тамыры кулланыла. 1 аш кашыгы вакланган тамырны 1 стакан суда сүрән утта 10 минут пешерәләр. 30 минут төнәткәч, сөзәләр, 1 аш кашыгын 1 стакан аракыга салып, эчкечегә эчерәләр. Яки порошок итеп төелгән тайтояк тамырын пычак очына әлеп эчкеченең ризыгына сибәләр. 3 тапкыр ашый икән – 3 тапкыр сибәләр. Әмма дозаны арттырырга ярамый, үсемлек агулы! Яисә 3 аш кашыгы вакланган тамырны 1 стакан суда 10 минут пешерәләр, көн дәвамында 2-4 әр аш кашыгын эчкеченең ашына һәм чәенә кушып бирәләр. 3 ай буе көн саен эчәргә кирәк.

23 май (дүшәмбе). ***Шәүвәл аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,1.45 сәгатьтә калка, 11.12 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.44 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карама

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

24 май (сишәмбе). ***Шәүвәл аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 1.55 сәгатьтә калка, 12.37 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.47 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Баллы сарымсак

Иммунитетны ныгыту, кан тамырларын чистарту һәм ныгыту өчен, 250 г сарымсакны иттарткычтан чыгарып, 350 г сыек бал кушалар, 1 атна тонәткәч, көненә 3 тапкыр, ашарга 40 минут кала, 1 әр аш кашыгы кабалар. Дәва курсы – 1-2 ай. 1 чәй кашыгы төелгән мөшкәт чикләвеген һәм 1 аш кашыгы балны 200 мл җылы суга салып, яхшылап болгатып, иртәнге ашка 1 сәгать кала һәм кичке аштан соң 2 сәгать үткәч берәр стакан эчү дә кан тамырларын ныгыта.

25 май (чәршәмбе). ***Шәүвәл аеның 24 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 2.04 сәгатьтә калка, 13.59 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.51 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

26 май (пәнҗешәмбе). ***Шәүвәл аеның 25 нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,2.11 сәгатьтә калка, 15.19 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.53 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

27 май (җомга). ***Шәүвәл аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,2.19 сәгатьтә калка, 16.38 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы16.56 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Ялкауларча пәхләвә

250 г атланмай, 4 йомырка, 1 стакан каймак, 3 стакан он, 150 г әстерхан чикләвеге, 100 г йөзем, 1,5 стакан шикәр, бер чеметем ванилин, серкә белән сүндерелгән әз генә сода кирәк. Атланмайны он белән уалар, каймак, 3 йомырка сарысы, сода кушып, камыр басалар, 4 тигез йомарламга бүлеп, 2 сәгатькә суыткычка куялар. Аннары һәркайсын 3әр миллиметр калынлыкта җәяләр. Эчлек әзерлиләр: 4 йомырка агын туглап күпертеп, төелгән чикләвек, йөзем, ванилин кушалар. 3 җәем өстенә эчлекне җәяләр, ә өске җәемгә 1 йомырка сарысын күпертеп сылыйлар. 180 градуслы газ мичендә 40 минут пешерәләр.

Кроссворд



Сулдан уңга:
5. Үрә торышта кузгалмаслык итеп җиргә казып утыртылган бүрәнә. 7. Читләтеп, мыскыллап, астыртын көлү. 8. Матур язучы, каллиграф. 10. Шук, наян. 11. Татарстандагы район үзәге. 12. Тавыш турындагы фән. 15. Дагыстанда яшәүче төрки халык. 17. Өч тавыш. 19. Иранда акча берәмлеге. 20. Термин. 21. Кешеләрне дулкынландыра торган берәр ялган хәбәр. 22. Ягар өчен хәзерләнгән агачлар. 24. Агачның эчке, кайры астындагы сүсле катламы. 25. Җил себереп ясаган кар өеме. 27. Буар еланнар семьялыгыннан иң эре елан. 30. Афәт, зур зыян. 32. Эре бөртекле нәрсәләрне төю өчен махсус савыт. 33.Бәдрәф бүлмәсе. 34.Бәпкә, кайчы. 35. Казак гаскәрләре башлыгы.

Өстән аска:
1. Өй стенасының югары өлешенә эленә торган тукыма, пәрдә. 2.Музыка коралы. 3.Гаскәри берәмлек. 4. Казанның волейбол командасы. 6. Кызыл яки кызгылт-сары төстәге каты минерал. 7.Аяк киеме. 9. Татарстанда яшәүче халыкның бер кешесе. 12. Тимербетон корылмаларның корыч каркас-кирәчләре. 13. Чүп савыты. 14. Организмда көч, чыдамлык тәрбияли торган физик күнекмәләр җыелмасы. 16. Тирән чокыр яки тарлавык аша коры җирдә салынган күпер. 18. Кеше психикасында теләкне тормышка ашыруда чагылган сәләте, аңлы омтылышы. 21. Кимерүчеләр отрядыннан артык зур булмаган җәнлек. 23. Тыныш билгесе. 24. Саксызлык аркасында төшереп калдыру. 26. Йөгерек, чапкын ат. 28. Язма рәвештә җибәрелгән рәсми дипломатик мөрәҗәгать. 29. Эш-хәлнең календарь вакыты. 31. Намазга чакыру. 32. Шактый зур гәүдәле диңгез кысласы.

Нияз БИШБАЛТА төзеде.

ҖАВАПЛАР

Сулдан уңга: 5. Багана. 7. Ирония. 8. Хаттат. 10. Шаян. 11. Апас. 12. Акустика. 15. Авар. 17. Трио. 19. Риал. 20. Атама. 21. Коткы. 22. Утын. 24. Юкәр. 25. Көрт. 27. Анаконда. 30. Каза. 32. Киле. 33. Туалет. 34. Атлама. 35. Атаман.

Өстән аска: 1. Кашага. 2. Баян. 3. Рота. 4. “Динамо”. 6. Ахак. 7. Итек. 9. Татар. 12. Арматура. 13. Урна. 14. Атлетика. 16. Виадук. 18. Ихтыяр. 21. Куян. 23. Нокта. 24. Югалту. 26. Тулпар. 28. Нота. 29. Дата. 31. Азан. 32. Краб.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

22 май – «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев).
24 май – «Исәнме, улым!» (Б.Абдуразззоков).
25 май – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
26 май – «Тамашачы тамашасы»
27 май – Зур залда – «Сәфәр» (А.Шакиров). Кече залда – «Киек каз юлы» (И.Мөхәммәтгалиев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

Р.Нуриев исемендәге XXXV халыкара классик балет фестивале

22 май – «Дон Кихот» (Л.Минкус).
23 май – «Анюта» (В.Гаврилин).
25 май – «Корсар» (А.Адан).
26 май – «Лебединое озеро» (П.Чайковский).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

20-22 май – «Кара пулат» (Р.Харис, Э.Низамов).
24 май – «Кияү урлау» (С.Юзеев, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
25 май – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
26 май – «Беренче мәхәббәт» (Х.Вахит).
27 май – «Полиционер» (И.Зәйниев).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

20 май – 13.00 – «Сәлам, Актәпи!» (А.Сальникова). 18.30 – «Тапшырыл...ган хатлар» (Г.Кутуй).
26, 27 май – Премьера. «Тимур һәм комета».

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

20 май – Зур залда 11.00, 13.00 – «Али-баба и сорок разбойников» (В.Смехов). Кече залда 11.00, 13.00 – «Цветик-семицветик» (В.Катаев). Зур залда 19.00 – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).
21 май – 11.00, 13.30 – «Мырау батыр» (Н.Исәнбәт). 12.00, 14.00 – «Али-баба и сорок разбойников» (В.Смехов).
22 май – Фойеда – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина). Зур залда – «Гусенок» (Н.Гернет).
24 май – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин).
25 май – «Страна чудес Алисы» (Л.Керролл әсәренә нигезләнеп куелган).
26 май – «Сказка о царе Солтане» (А.Пушкин).
27 май – Зур залда – «Приключения Барона Мюнхгаузена» (Р.Э.Распе). Кече залда – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

20 май – «Мунча ташы» эстрада миниатюралары театры концерты.
23 май – «Байкал» Бурят милли җыр һәм бию театрының «Моя Бурятия» дип исемләнгән концерты.
26 май – «Вайнах» дәүләт бию ансамбле концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

23 май – «StellArt TRIO» төркеме башкаруында Людвиг ван Бетховен, П.И.Чайковский музыкалары яңгырый.
27 май – «La Primavera» камера оркестрының XXXII иҗат сезонын ябу концерты.

Мансур Вәлиев–Баржылы кытыклары

Хәтта Зөлфәт аптырады



Шагыйрь Зөлфәт, зур шигъри таланты өстенә, шәхес буларак та гаять кызыклы, бик тә йөгерек зиһенле, уен-көлкегә маһир, чып-чын егет кеше иде... Бервакыт шулай Бауман урамында-гы Язучылар берлегенең пропаганда бюро-сы ишеге төбендә Эльс Гадел, Зөлфәт һәм мин төшке ашка барыр алдыннан юк-бар сүз сөйләшкәләп торабыз. Бермәлне Зөлфәт болай дип әйтеп куйды:

– Карәле, Рафаил Сәхәби опера театрында эшли башлаган икән бит!

Мин инде студент чагында ук бу театрга шактый еш йөргән кеше – болай дип төп-ченмәкче булдым:

– Нинди партия бирделәр микән соң?

Ә бу сорау Зөлфәткә аяз көнне яшен яшьнәгәндәй тәэсир итте, ул бө-тенләй аптырап калды. Шагыйрь кешегә опера-балетларны, аларда һәрбер артистның нинди пар-тияләр җырлаячагын белү дә мәҗбүри түгел бит инде!

Эльс Гадел исә хәлне тиз аңлап алды һәм үз кешеләр булгач иркенләп, рәхәтләнеп көлә башлады. Ирексездән, безгә дә аңа кушылып хихыл-дарга туры килде.

Әмирхан ага Еники сөйләгәндә

1980 еллар тирәсендә Татарстан Язучылар берлеге аппаратында эшли башлагач, миңа күп каләм әһелләре белән аралашырга туры килде.

Әмирхан ага Еники минем кайсы яктан икәнне белгәч, анда булуын искә төшерде.

– Чулман елгасыннан ерак түгел утырган Салагыш дигән авылга барып чыктык бермәл, – дип сөйләп китте ул. – Колхоз җитәкчесе үзе пристаньга килеп каршы алды, очрашулар булды, бик әйбәт кунак иттеләр...

Бу инде минем әнинең абыйсы Габдрахман ага Җәләев турында сөйли. Мин дәшмичә генә тыңлап утырам. Мактап сөйли бит.

– Икенче көнне күрше авылга үзе үк озатып куярга булды. Ат җигеп, тарантаска утырып. Юлда барганда бер апаны куып җиттек. Мин әйтәм, туктап утырта инде бу апаны, дим. Әмма шиш, уздык та киттек теге апаны. Утырту да юк, туктау да юк!..

Әмирхан ага хәзер инде колхоз рәисенең бу гамәлен ошатмыйча сөйли. Ә мин һаман сиз-дермим. Теге рәиснең минем әнинең абыйсы булганлыгын ничек әйтим инде! Шулай итеп, миндә Габдрахман ага өчен уңайсызлану тойгысы торып калды. Әмма соңрак уйлый башладым: «Колхоз рәисе янына килеп утырамы соң инде теге апа? Үзенең аякларына ышанып юлга чык-кан бит ул. Әле буй җитмәстәй зур кунагы да бар колхоз рәисенең!»

Хәзер дә уйлап куям: безнең як кешеләре китап кушканча зыялы була белми шул!

Шаян мизгел

Үтеп киткән совет чорыннан әйбәт истәлекләр күп инде ул. Шуларның берсе – май ахырларында Идел буендагы лагерьда иҗат яшьләренең бер атналык ялын оештыру. Анда кадерле очрашулар да, төрле-төрле лек-цияләр дә булды. Өлкән яшьтәге иҗат әһелләре яшьләргә хәер-фатыйха да бирде. Кыскасы, атна буена Идел буе шаулап-гөрләп торды. Ә менә бу шаян кадрда исә тәнкыйтьче Мансур Вәлиев шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовка «бүләк итеп» галошлар тапшыра. Чыннан да, алар икесе дә «Аккош күле»ндә яши бит. Анда галош бик кирәкле малдыр – урманга гөмбәгә чыксаң да, якындагы Тирән күлгә су коенырга төшсәң дә, якындагы тук-талышка киләсе кунагыңны каршыларга барсаң да – гел дә аякта галош була. Шуңа күрә галош булганга икесе дә бик шат. Ә менә ул галошның каян килеп чыгуын беркем дә белми. Бу тарихи кадрның авторы, фотографы да билгесез. Ә вакыты – 1976 ел.

Нәби Дәүли ядкәре

Мин инде 45 еллап язучыларның «Аккош күле» авылында яшим. Җәен дә, кышын да шунда... Шуңа күрә аңа килгән күренекле шәхесләр турында кызыклы истәлекләр дә күп. Менә берсен, Нәби ага Дәүли турындагысын гына искә алыйм әле.

Нәби аганы безнең халык күбрәк «Үлем белән яшәү арасында» әсәре аша белә. Немец әсирлеге турында тетрәндергеч әсәр. Әлбәттә, Нәби аганың башка китаплары да бар, җырлары да күп...

Бер җәйнең матур иртәсендә Нәби ага мине күл буена таба чакыра бит, «әйдә» дә «әйдә» генә!

Безнең яндагы Кече Тирән күл янына төшеп җиттек. Шунда Нәби ага өс киемнәрен салып атты да, суга кереп китте. Һәм суга баткан бер черек агачка барып та тотынды бу! Миңа да кычкыра:

– Әйдә, булыш! – ди.

Мин дә эшне аңлап алдым – Нәби ага судагы черек агачлар өчен борчылып йөргән икән! Алар үз черекләре белән безнең суны агулый бит!

Ул көнне без Нәби ага белән байтак изаландык. Чөнки агачлар-ның күбесе аска ук төшеп киткән, аларны ярга тартып чыгару өчен дә байтак гайрәт һәм түземлек кирәк!..

Күп еллар үтеп китте, тирән күл өстен янә черек агачлар бас-ты. Хәзер күл буена төшкән саен Нәби ага күз алдына килә. Ул һаман да: – Әйдә әле! – дип дәшә һәм безне булдыксызлык өчен кыздыра да сыман...

Кайсы башлырак?

Америкадагы Вандербильт университеты галимнәре озак еллар буе үткәргән тикшеренү этнең баш мие кабыгындагы нейроннар санының мәченекенә караганда икеләтә артыграк булуын күрсәткән. Эт миенең фикерләү һәм планлаштыру өчен җавап бирә торган өлешендә якынча 530 миллион, мәченекендә 250 миллион нейрон бар икән. Экспертлар фикеренчә, хайваннарның үз тәҗрибәсен истә тотып нәтиҗә ясау сәләте нәкъ менә нейроннар санына бәйле. Чагыштыру өчен кеше миендәге нейроннар саны да китерелә – алар якынча 16 миллиард тәшкил итә. Нейробиолог Сюзанна Геркулано-Хоузель фикеренчә, мәчеләрне дә акылсыз хайван дип әйтеп булмый, әмма маэмайлар катлаулырак бурычларны хәл итәргә сәләтле. Проект кысаларында галимнәр аю, янут, мангуст, сыртлан, арыслан һәм сасы көзәннәрнең дә баш миен өйрәнгән. Янут миендәге нейроннар саны да этнеке кадәр икәне ачыкланган.

(“The Washington Times”).

Картлар авылы

Өлкән яшьтәгеләр еш кына деменциядән интегә, чөнки картайган саен акыл үткенләнә бармый, киресенчә, зәгыйфьләнә. Элегрәк алган белемне җую һәм игътибарны туплый алмау планетабыздагы берничә дистә миллион кешегә хас. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматлары буенча, 2030 елга кадәр деменциядән интегүчеләр саны ике мәртәбә артачак һәм 65 миллионга җитәчәк, 2050 елга кадәр исә өч тапкыр артачак. Нидерландта әлеге проблеманы хәл итүнең бик уңышлы юлын тапканнар. Веесп шәһәре читендәге Хогевейк авылы беренче карашка башкаларыннан бернәрсә белән дә аерылып тормый – супермаркетлары да, ресторан-парклары да, хәтта театры да бар. Әмма бу авылда деменциядән интегүче 152 кеше генә яши. Бирелә алар өчен 23 йорт төзелгән һәм аларны тәүлек әйләнәсе күзәтү оештырылган – табибләр һәрвакыт кизү тора, картларны барлыгы 240 кеше кайгырта. Күпсанлы тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, авыл халкына дарулар бик аз кирәк икән. Алай гына да түгел, биредә яшәүчеләр гадәти картлар йортларындагы яшьтәшләреннән күпкә активрак. Авылны нигездә дәүләт кайгырта – 22 миллион доллар бирә, калган 3,5 миллионны исә, кунакка килүчеләр өчен ресторан һәм кафе ачып, театр бинасын арендага биреп, авыл җитәкчелеге үзе таба.

(“The Mirror”).

Йөрәккә бәрә

